وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

Дин вә Мәгыйшәт

№5 (226). Май / Рәҗәп – 1435

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



2 бит

ИСЛАМ ДИНЕН РӘСМИ КАБУЛ ИТҮ КӨНЕ БЕЛӘН!

4 бит

ГЫЙЛЕМ – АЛЛАҺНЫҢ ОЛУГ НИГЪМӘТЕ



8 бит

МАТУР БУЛЫГЫЗ, ШӘРИГАТЬ КАНУННАРЫН ГЫНА БОЗМАГЫЗ

9 бит

ШАТЛЫКТА ДА, КАЙГЫДА ДА БЕРГӘ БУЛЫЙК!

ИСЛАМ ДИНЕН РӘСМИ КАБУЛ ИТҮ КӨНЕ БЕЛӘН!

21 нче май - республикабызда Идел буе Болгар дәүләтенең 922 нче елда Ислам динен рәсми кабул иткән көне буларак билгеләп үтелә. Шунысы да мәгълүм, Аллаһы Тәгалә ихтыяры белән бабаларыбыз ислам юлын бу вакыттан күпкә иртәрәк чорда сайлаган. Бүгенге көннәргә кадәр сакланып килгән тарихи чыганаклар шул хакта сөйли. Бүген без, Аллага шөкер, менә шул юлны дәвам итүчеләрдән. Исламның күркәмлеген бабаларыбыз кебек үк аңларга, рухи мирасыбыз хикмәтенә төшенергә һәм аны үзебездән соң килгән буынга җиткерергә тырышабыз.

Ислам динен рәсми кабул иткән көн ул - мөселманнарның Россиядә җирле халык булуына да бер дәлил. Күп гасырлар дәвамында илебездә мөселман өммәте динебезгә таянып эш йөрткән, тормышларын алып барган.

Дин - бар буын кешеләре өчен дә Аллаһы Тәгаләнең нәсыйхәте, нигъмәте. Күп гасырлар дәвамында ислам татар халкының алга алып баручы рухи көче, иманы булган һәм җәмгыятьнең әдәп-әхлак нигезен тоткан. Алга таба да, иншә Аллаһ, шулай булырга язсын. Барчабызга да Раббыбызның иксез-чиксез рәхмәтләренә ирешергә, гомерләребезне хәерле итеп үткәрергә насыйп итсен! Ил-көннәребезгә тынычлык-иминлек, бәрәкәт бирсен иде!

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН

ТАТАРСТАН МӨФТИЕ РОССИЯ ИҖТИМАГЫЙ ПАЛАТАСЫ САЙЛАУЛАРЫНДА КАТНАША

1 нче майдан Россия Иҗтимагый Палатасының яңа әгъзаларына интернетта тавыш бирергә мөмкин. Шулай итеп, Россия гражданнары беренче мәртәбә үзләре интернет ярдәмендә Иҗтимагый Палата әгъзаларын сайлый.

Һәр кеше 14 төрле юнәлештәге эшчәнлек буенча берәр кандидатка тавыш бирә ала. "Милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрне саклау, тынычлык һәм үзара килешүгә булышлык күрсәтү" юнәлешендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнаша.

Мөфтигә тавыш бирү өчен түбәндәге сылтамага керергә кирәк:

https://oprf.roi.ru/441/

Уртаклашырлык саллы тәҗрибәбез бар

Казанның Әл-Мәрҗани мәчетендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Идел буе федераль округы төбәкләрендә милли һәм дини мөнәсәбәтләргә җаваплы вәкилләрне Татарстан мөселманнары эшчәнлеге, мөмкинлекләре белән таныштырды. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм Россия ислам институты эшчәнлегенә презентация шушы көннәрдә Казанда үткәрелүче этно-конфессияара мөнәсәбәтләр буенча семинар-киңәшмә кысаларында уздырылды.

Чарада мөфти урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, РИИ ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин, Татарстан Президентының эчке сәясәт мәсьәләләре департаментының дини оешмалар белән элемтә идарәсе җитәкчесе Илнур Гатауллин һәм башкалар катнашты.

Камил хәзрәт рәсми кунакларга нәзарәтнең дини мәгариф, иҗтимагый эшләр һәм мәгърифәтчелек юнәлешендә алып барган эшләре хакында сөйләде. "Хузур" нәшрият йортының уңышлары хакында җиткерде.

Бүгенге көндә республика дини уку йортларында районнардан һәм төбәкләрдән җыелган 3 меңгә якын шәкерт белем ала. ТР МДНнең уку-укыту методик берлеге төзелде. Берлек ислам һөнәри дини мәгарифен үстерү концепциясен эшләде. Татарстанда нәшер ителүче дини китапларны тикшерү буенча ТР МДНнең эксперт советы булдырылды. Татар дини мирасын торгызу һәм тарату, танылган хәнәфи мәзһәбе галимнәренең гарәп һәм төрек телләрендәге хезмәтләрен тәрҗемә итү эше алып барыла. Мөселман дини мәгарифенең сыйфатын күтәрү максатыннан 2014-2015 нче уку елларында татар, классик (гарәп телендәге китаплар буенча) укыту системасына күчү каралды, гарәп телендәге китаплар исемлеге билгеләнде. Мәдрәсәләрне тәмамлаучыларга, яшь имамнарга авыл җирлегендә эшләү өчен грантлар бирә башлау исә яшь белгечләрне дини эшчәнлеккә тарту булып тора.

Мөфтият мәхәлләләрдә "Исламда иҗтимагый эшчәнлек" идеясен таратуга һәм мөселман оешмаларының иҗтимагый эшчәнлегенә зур әһәмият бирә. Иҗтимагый хезмәт ТР МДНнең өстенлекле юнәлеше булып тора. Иҗтимагый юнәлештә тормышка ашырырга ниятләнелгән проектлар да зурдан: ятим гарип балаларны тернәкләндерү үзәген, эчкечелеккә һәм наркотик матдәләргә бәйлелеккә төшүчеләрне профилактикалау үзәген, иреккә чыккан тоткыннарны тернәкләндерү үзәген ачу һәм башкалар.

Бабаларыбызның мәгърифәтчелек эшен дәвам итеп, дистәләгән китаплар, буклетлар бастырыла. 2013 нче елда нәзарәтнең "Хузур" нәшрият йорты ачылды. Нәшрият йорты гомуми тиражы 136 мең данә белән 27 китап бастырды. Моннан тыш Татарстан имамнары өчен кварталга бер тапкыр татар телендә күләме 300-400 битлек булып, тиражы 2000 данә белән "Шура" журналы чыга. Анда җомга вәгазьләре, актуаль сорауларга җаваплар, мәкаләләр, ислам тәгълиматчылары язмалары, тарихи очерклар, иске татар телендәге текстлар бастырыла. Шулай ук 13 мең тираж белән ай саен "Дин вә мәгыйшәт", "Умма" газеталары дөнья күрә.

ТР МДН традицион ислам кыйммәтләрен дәгъвәтләү һәм имамнар гыйлемен күтәрү белән дә актив шөгыльләнә. Бу максаттан Татарстанның барлык мәчетләренә бердәм җомга вәгазьләрен сөйләү кертелде; төзәтү учреждениеләрендә даими рәвештә хәнәфи мәзһәбе буенча вәгазьләр укыла; дәгъвәт бүлеге белгечләре республика районнарында вәгазь кичәләре уздыра.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт үзенең чыгышында мөфтиятнең эшчәнлеге татар халкының рухи мирасын торгызуга, республикада төрле дин вәкилләренең үзара тату һәм тыныч яшәвен саклауга һәм динебез кыйммәтләрен халыкка җиткерүгә юнәлгәнлеккә басым ясады.

Россия ислам институты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин Россиядә алдынгы югары дини гыйлем бирүче уку йорты хакында сөйләде. Рәфыйк әфәнде биредә барлык Идел буе төбәкләре имамнары өчен югары дәрәҗәдәге курслар оештырылуга аерым игътибар юнәлтте. Ул төрле төбәкләрдә эшләүче татар имамнарының гыйлемен Казанда ныгытырга чакырды.

Презентация кысаларында рәсми кунаклар нәзарәт вәкилләренә үзләренең сорауларын бирделәр. Шулай ук Казан шәһәре имам-мөхтәсибе Мансур хәзрәт Җәләлетдинов кунакларны Әл-Мәрҗани мәчете белән таныштырды һәм иман йорты тарихы хакында сөйләде.

Презентация Татарстан мөселманнарының дини эшчәнлеген күрсәтү белән бергә, рухи байлыгыбызны, мирасыбызны саклауда яңа юллар табылуын һәм өммәтебезнең потенциалы, башкалар белән уртаклашырлык саллы тәҗрибәсе барлыкны да күрсәтте.

Айзирәк ГӘРӘЕВА

"НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ" ANDROID ҺӘМ OIS ПЛАТФОРМАСЫНДА

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең "Хузур" нәшрият йорты, Россиядә беренче булып, смартфоннар өчен татар телендәге "Намаз вакытлары" программасын гамәлгә кертте. Android һәм OIS платформалары өчен махсус эшләнгән "Намаз вакытлары" татар телендә Татарстанның барлык районнары өчен көйләнгән. Хәзер теләгән һәркем әлеге кушымтаны үзенең смартфонына йөкләп, ТР МДНнең Голәмалар шурасы КФУның астрономия кафедрасы белән берлектә әзерләгән намаз вакытлары белән оффлайнда таныша ала. Программада шулай ук намаз хакында язма, кыйбланы күрсәтүче компас, намаз вакытын искәртүче будильник урнаштырылган.



БЕРЕНЧЕ "ХӘЛӘЛ" РЕСПУБЛИКА ЯРМИНКӘСЕНӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

24 нче майда "Казан" авыл хуҗалыгы министрлыгы сәнәгать паркында (Аграрная ур., 2 нче йорт) беренче тапкыр "Хәләл" республика ярминкәсе уздырыла. Ярминкәдә республика җитештерүчеләренең хәләл ризыклары: ит һәм сөт, кондитер һәм башка төр продуктлар сатылачак.

Әлеге чараны Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, ТР МДНнең "Хәләл" комитеты, "Казан" агросәнәгать паркы, "Хәләл" индустриясе милли ассоциациясе оештыра.

ӨЧ СӘХАБӘ ТУРЫНДАГЫ РИВАЯТЬТӘ ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МӘДӘНИ КОДЫ ЯШЕРЕЛГӘН

ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ КӨЗГЕСЕ

Борынгы болгарларга ислам динен алып килгән Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) өч сәхабәсе турындагы борынгы риваять татар дөньясында күптән бәхәсләр тудырып килә. Берәүләр аны - уйдырма дип, ә икенчеләре тарихи факт дип атый. Болгар шәһәренең изге урыннарын торгызу һәм анда борынгы риваятьләр мотивлары буенча истәлекле монумент кую сәбәпле бу бәхәс тагын да зуррак көч белән купты. Монументта, риваятьтә әйтелгәнчә, сәхабәләр үзләре белән Идел буйларына алып килгән юл таягы, кара савыты һәм чалма сурәтләнгән.

Әлеге тема буенча күбесенчә тарихчылар баш ваталар, чөнки бәхәс, гадәттә, тарихи күзлектән чыгып караганда, бу вакыйганың булу-булмавы, чын яки уйдырма булуында. Минемчә, бу сюжетка башка яктан чыгып карарга кирәк, чөнки ул безнең үткәнебез турында булудан бигрәк, татар халкының бүгенге көне турында. Анда бүгенге заман татарларының менталлеген билгеләгән безнең рухи тарихи мәдәниятебезнең мәгънәви коды, символы яшерелгән. Башкача әйткәндә, бу риваять үзенчәлекле көзге сыман, бу көзгегә карап, без үз-үзебезне яхшырак аңлый алабыз. Ләкин бу көзгедә үзебезнең чагылышыбызны күрер һәм анда яшерелгән символларны аңлар өчен, Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) өч сәхабәсе турындагы риваятькә тарихи күзлектән түгел, ә дини тәгълимат культурологиясе ягыннан карарга кирәк.

БОЛГАРЛАРНЫҢ ИСЛАМ ТАРИХЫ

Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) өч сәхабәсе турындагы риваять болгарлар ислам динен кайчан кабул иткән дигән сорауны тудыра. Рәсми рәвештә дәүләт дәрәҗәсендә бу вакыйга 922 нче елда булган, бу турыда Ибн Фадлан җентекләп тасвирлый. Ләкин чынлыкта болгарлар ислам динен алданрак кабул иткәннәр. Мәсәлән, Шиһабетдин Мәрҗани моның рәсми рәвештә теркәлгәнгә кадәр 100 ел алдан булганлыгы турында әйтә. Әгәр дә Пәйгамбәребез (с.г.в.) сәхабәләре болгарлар янына килгән икән, димәк, бу тагын да элегрәк, VIII гасырдан да соңрак булмаган. Мөмкин хәлме бу?

XIX гасырның күренекле слависты Павел Йозеф Шафарик көтелмәгән фактларны ача. Ул христиан динен кабул иткәнче болгарлар (Идел буе болгарлары белән кардәш, хәзерге Болгария дәүләтендә яшәүче халык) ислам динен тотканнар дигән ачыш ясый. Моңа дәлил итеп, 865 нче елда көчләп христианлаштырганчы болгарларда булган гореф-гадәтләрне китерә: "аякларны диңгездә юу", "төрекләр кебек киң ыштаннар киеп йөрү, фарсылар кебек аякларны бөкләп үкчәләрдә утыру, сул якка караганда уң якка өстенлек бирү". Бу турыда словак-чех тикшеренүчесе үзенең "Славянские древности" дип аталган ике томлык фундаменталь хезмәтендә яза.

Бу чорның кызыклы бер документы булып, Рим папасы Николай I нең болгарларның христианлаштырылгач биргән сорау хатларына язган җавабы тора. Сораулар язылган хат сакланмаган. Ләкин Рим папасының болгарларны борчыган сорауларга биргән җавап хаты сакланган. Бу сорауларда да мөселманча яшәү рәвеше чагыла. IX гасырда яшәгән болгарлар католик чиркәү башлыгыннан сугыш тыелган айлар, никах уку тыелган туганлык мөнәсәбәтләре, кәләшкә бирелергә тиешле бүләк, күпхатынлылык, пычаксыз үтерелгән хайванның итен куллану, сәдака бирелергә тиешле кешеләр, башка киеп йөри торган җитен бәйләвеч (чалма), сарациннардан (мөселманнардан) калган китаплар белән ни эшләргә кирәклеге турында сорыйлар. Мөселман фикыһын өйрәнгән кеше бу сорауларда шәригать проблематикасын тиз күрә. Ләкин башкасы кызык - борынгы болгарларның мөселманлашу каналы. "Дунай болгарларының, - дип яза Шафарик, - үзләре Мизиядә урнашкач та, Идел буенда калган, аларга VIII гасырда ук ислам дине нигезләрен биргән кардәшләре белән дустанә мөнәсәбәтләрне саклап калулары ихтимал". Бу нәтиҗә безнең темага мөнәсәбәттә Идел буе болгарлары VIII гасырда ук кардәш халыкны ислам диненә керткәннәрен аңлата, димәк, үзләре алар ислам динен Пәйгамбәребез (с.г.в.) сәхабәләре чорында ук кабул иткәннәр.

ТӨШ – УЙДЫРМАМЫ ӘЛЛӘ ЧЫНБАРЛЫКМЫ?

Идел буе болгарлары ягына сәхабәләрнең килү-килмәве турындагы бәхәсне профессиональ тарихчылар карамагына калдырыйк. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) өч сәхабәсе турындагы риваять, тарихчылар нинди нәтиҗә чыгарса да, безнең өчен гаять зур әһәмияткә ия. Әгәр дә бу риваять уйдырма булып чыкса, ничек итеп ул үз кыйммәтен саклап кала алачак соң?

Моны аңлар өчен кеше төшләрен анализлауга фәнни яктан килеп карау белән параллель уздырырга кирәк. Без бу өлкәдә дә "Төш - уйдырмамы әллә чынбарлыкмы?" дигән сорауга җавап эзлибез. Бер яктан, аның сюжеты һәм образлары - уйдырма. Икенче яктан, төштә безнең психикабызның төбендә булган, күзәтүгә бирелмәгән аңсыз процесслар чагылыш таба. Зигмунд Фрейд дәлилләвенчә, төш безгә психикабызның иң төбендә булган катлауларны күрү мөмкинлеген бирә.

Мәдәниятнең коллектив образлары, аерым бер кеше төше кебек үк, үзләрендә яшәешнең яшерен катламнарын гәүдәләндерә, ләкин аерым кешенекен түгел, ә бәлки, гомум җәмгыятьнең. Менә шуңа күрә мифлар, легендалар, әкиятләр, хәтта анекдотлар да аларны тудырган мәдәниятне аңлар өчен зур әһәмияткә ия. Бу яктан караганда, Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) өч сәхабәсе турындагы риваять татар халкының рухи мәдәнияте, безнең менталлекнең тарихи нигезләре турында күп нәрсә сөйли ала. Иң мөһиме - символларны укый белергә кирәк.

ФӘН ҺӘМ ДИН ХАКЫЙКАТЕ

Монда без фән һәм дин хакыйкатьләре арасындагы аермалыкларга якын киләбез. Күпләр чын күңелдән алар арасында булган аермалыкларны аңлый алмыйлар, чөнки алар бу ике дөньяны капма-каршы куялар. Чынлыкта исә, фән һәм дин кешеләргә төрле өлкәләрдә булыша, үзара кисешмиләр. Фәннең төп максаты - "Ничек?" соравына җавап бирү. Нәкъ менә шул сорауга җавапта теләсә нинди технологияләр нигезе ята. Дин исә "Нәрсә өчен?" соравына җавап бирә. Аның максаты - кешеләргә яшәешнең аңлы дәрәҗәсенә чыгарга булышу. Аларның аермасы үткәнгә караштa. Тарих фәне беренче чиратта күренешләрнең фактик торышы белән кызыксына. Чынлыкта ничек булуын ачыклый. Ә динне беренче чиратта кешегә рухи яктан үсәргә ярдәм иткән тарихи риваятьләрдән чыккан сабаклар, әхлак, үгет-нәсыйхәт кызыксындыра.

Нух пәйгамбәр заманында булган су басу турындагы сюжетны очраткач, тарихчы аны бәяләр өчен, түбәндәге сорауларга җавап эзли: бу су басу бөтен җирдә дә булганмы, әллә бер җирдә генә булганмы; хайваннар ни рәвешле җыелганнар һәм ничек исән калганнар; бу мөмкин хәлме, әллә юкмы һ.б. Динне исә, бу сораулар кызыксындырмый. Дин тәгълиматы өчен су басу турындагы тарих - кешелекне начар гамәлләр кылудан кисәтү, чөнки без бу мисалда кылган начарлык үзебезгә үк әйләнеп кайтачагын күрәбез. Нәкъ шулай ук кеше барлыкка килүне өйрәнгәндә дин, фәннән аермалы буларак, аның "механикасы" белән кызыксынмый. Дин белгечләренең балчыктан ни рәвешле кеше ясалганлыгы турында җентекләп язылган аңлатмалары юк. Ә балчыктан ясалган Адәмнең аңа Аллаһы Тәгалә җан өргәч тере булып китүе турындагы хикәя безгә кешенең физик тән генә булмавы, ә Аллаһы Тәгалә өргән җан да булуы турында гыйбрәт тә. Димәк, безгә яшәешнең матди ягын гына түгел, рухи ягын да кайгыртырга кирәк. Дини метафораларга бу яктан караганда фән һәм дин арасында бернинди бәхәс туа алмый.

ТРАДИЦИОН ИСЛАМНЫ НИЧЕК ТАНЫП БУЛА?

Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) өч сәхабәсе турындагы риваятькә без шулай ук карый алабыз. Төп сорау булып монда вакыйганың булу-булмавы, булса, ничек булуы түгел, ә бу сюжеттан нинди гыйбрәт, нинди нәсыйхәт чыгуы тора. Ул безгә үзебезне, мәдәниятебезне яхшырак аңларга һәм яхшы якка үзгәрергә булыша. Риваятькә безгә рухи тормышыбызны дөрес төзергә ярдәм иткән нәсыйхәтләр салынган. Минем фикеремчә, бу риваятьнең кыйммәте нәкъ менә шунда да инде.

Алга таба китеп, шуны искәртәсем килә: риваятьнең төп образлары - чалма, юл таягы һәм кара савыты - Пәйгамбәрдән (с.г.в.) килгән исламның символлары, шуңа күрә татар халкының рухи юлында ориентир булып тора алалар. Әгәр дә без Пәйгамбәрдән (с.г.в.) килгән исламның нинди булуын аңларга телибез икән, безгә бу символларда яшерелгән мәгънәне аңларга кирәк. Шул очракта традицион исламның нинди булуын аңлаячакбыз.

Рөстәм БАТЫР,
Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары

ГЫЙЛЕМ - АЛЛАҺНЫҢ ОЛУГ НИГЪМӘТЕ

Муһавия (радыйаллаһу ганһү) тапшырган хәдистә болай диелә: Аллаһның Рәсүле (салләллаһу галәйһи вәссәлам) әйткән: "Аллаһ бәрәкәт бирәм дигән кешесен дингә аңлауга ирештерер" (Бохари, Мөслим).

ДИННЕ АҢЛАУ - гыйбадәт кылу нигезләрен: ни өчен без бары тик Аңа гына гыйбадәт кылырга, Аның күрсәтмәләрен үтәргә тиеш икәнлегебезне, Аллаһы Тәгаләнең бәндәләрне ни өчен яралтканын, бу дөньяда безнең ни өчен яшәвебезне аңлау ул. Нәрсәне дә булса аңлау өчен, әлбәттә, аның турындагы белемнәргә, гыйлемгә ия булырга кирәк. Гыйлемнән башка без Аллаһы Тәгалә хак мөселманнарга вәгъдә иткәннәрнең меңнән берен дә аңлый алмыйбыз.

Аллаһы Тәгалә болай дигән:

فَتَعَالَى اللَّهُ الْمَلِكُ الْحَقُّ وَلَا تَعْجَلْ بِالْقُرْآنِ مِن قَبْلِ أَن يُقْضَى إِلَيْكَ وَحْيُهُ وَقُل رَّبِّ زِدْنِي عِلْمًا

"Аллаһы Тәгалә затында вә сыйфатында мәхлуктан бөек булды, Ул һәрнәрсәгә хаклык белән хуҗа булды, Җәбраил вәхине укып тәмам итмәстән элек, онытырмын дип укырга ашыкма. Ягъни, фәрештә укыганда аның белән бергә укыма, бәлки тыңлап тор. Дәхи Раббым белемемне арттыр диген!" (Коръән, 20:114).

Без гыйлемгә омтылырга тиешбез. Мөхәммәд пәйгамбәр (салләллаһу галәйһи вәссәлам) әйткән: "Ике (сыйфатка) (ия булган) кешеләрдән тыш, башка беркемнән дә көнләшмә. Ул кешеләрнең берсе - Аллаһ аңа байлык биреп, ул аны берни калдырмыйча тиешенчә тотып бетерә белгән кеше; икенчесе - Аллаһ аңа зирәклек биреп, ул (шул зирәклек) нигезендә хөкем кыла белгән һәм аны (башкаларга) тапшыра алган кеше". (Хәдисне Мәсгуд (р.г.), Бохари, Мөслим тапшырган.)

Мөхәммәд пәйгамбәр (салләллаһу галәйһи вәссәлам) гыйлем эстәгән вакытта безгә тырыш һәм зәлекле булырга кушкан. Кешенең белем туплавы тугганнан башлап аның вафатына кадәр дәвам итә. Шул кыска гына вакытта без файдалы белемнәрне мөмкин кадәр күбрәк алып калырга тырышырга тиеш. Ул белемнәрнең нәкъ менә файдалыларын, чөнки бер файдасыз, бер мәгънәсез, кирәксез, ә кайвакытта зыянлы да булган белемнәр бик күп. Бүгенге көндә теләсә нинди мәгълүматны табып алу бик җиңел. Ләкин бу һич кенә дә аны өйрәнергә, үзләштерергә кирәк дигәнне аңлатмый әле. Бер мәгънәсез ялган фәннәр, наркотиклар, исерткеч һәм миңгерәтүче матдәләр, корал әзерләү турындагы мәгълүмат - файдасыз гына түгел, ә зыянлы да, алар турында белемнәр туплау - гөнаһ. Хәзерге вакытта иң куркынычы - андый мәгълүматны безнең балаларыбыз да ала ала. Шуңа күрә дә һәр ата-ананың бурычы - кечкенә вакыттан ук балаларына дөрес тәрбия бирү, мәҗбүр итмичә, дингә тискәре караш формалаштырмыйча, аларны кирәкле, файдалы белемнәр генә биреп үстерү. Бу вакытта балалар белән йомшак мөгамәлә кылырга, үгет-нәсыйхәтләр белән, һәм, әлбәттә, үзеңнең шәхси үрнәгең белән эш итәргә кирәк. Безнең балаларыбызның беренче укытучылары - үзебез. Без аларны намаз укырга, гыйбадәтнең башка төрләренә өйрәтергә, алар белән бергә Коръән укырга тиешбез. Белем бер буыннан икенчесенә тапшырылып барырга тиеш.

Гыйлемнәргә өйрәткәндә һәрбер укучының үз остазы булуы мөһим. Кабатлап әйтәм: белем тапшырылып барырга тиеш. Остаздан - укучысына. Һәм шулай бөрләксез, Мөхәммәд пәйгамбәрдән (салләллаһу галәйһи вәссәлам) алып - Кыямәт көненә кадәр. Гыйлемгә ия кешенең өстенлекләре турында Коръәндә дә күп әйтелгән, бу турыда хәдисләр дә җитәрлек. Аллаһы Тәгалә әйткән:

أَمَّنْ هُوَ قَانِتٌ آنَاءَ اللَّيْلِ سَاجِدًا وَقَائِمًا يَحْذَرُ الْآخِرَةَ وَيَرْجُو رَحْمَةَ رَبِّهِ قُلْ هَلْ يَسْتَوِي الَّذِينَ يَعْلَمُونَ وَالَّذِينَ لَا يَعْلَمُونَ إِنَّمَا يَتَذَكَّرُ أُولُو الْأَلْبَابِ

"Әмма кичләрдә озын вакыт кыямда торып, сәҗдә кылып, Аллаһка гына гыйбадәт кылган мөэмин, ул ахирәт газабыннан куркып, Раббысының рәхмәтенә өмет итәдер <...> Кешеләргә әйт: "Батылны белеп батылдан ерак булган, хакны белеп хак тарафында сабит булган хак мөэминнәр, батылны да, хакны да белмичә адашып йөргән сукырлар белән бертигез булырлармы? Хакны батылдан аеру хакында саф гакыллы кешеләр генә вәгазьләнер һәм батылдан бизеп хакны кабул итәр" (Коръән, 39:9).

Коръәндә без тагын шундый юлларны укый алабыз:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِذَا قِيلَ لَكُمْ تَفَسَّحُوا فِي الْمَجَالِسِ فَافْسَحُوا يَفْسَحِ اللَّهُ لَكُمْ وَإِذَا قِيلَ انشُزُوا فَانشُزُوا يَرْفَعِ اللَّهُ الَّذِينَ آمَنُوا مِنكُمْ وَالَّذِينَ أُوتُوا الْعِلْمَ دَرَجَاتٍ وَاللَّهُ بِمَا تَعْمَلُونَ خَبِيرٌ

"Ий мөэминнәр, әгәр сезгә мәҗлесләрдә киңлек кылыгыз диелсә, киңлек кылыгыз, кергән кешеләргә урын бирегез һәм хакны сөйләргә вә тыңларга да ирек бирегез, Аллаһ сезгә җәннәттә киңлек кылыр, әгәр таралыгыз диелсә, эшләрегезгә таралыгыз, сездән иман китереп итагать иткән вә белем иясе булган мөэминнәрне Аллаһ дәрәҗәләргә күтәрер, Аллаһ сезнең кылган эшләрегездән хәбәрдардыр" (Коръән, 58:11).

Инде алда әйтеп кителгәнчә, һәр гыйлем алучының, гыйлем алуның кайсы гына этабында булмасын, зирәк остазы булуы мөһим. Ул ислам белән даими шөгыльләнүче кешеме, әллә инде Коръәнне өйрәнә генә башлаган башка берәүме, үзе өчен яңа чыганаклар табып, югарырак дәрәҗәдәге белемнәрне үзләштерүчеме - аның өйрәтеп, туры юлга кертеп җибәрерлек остазы булырга тиеш. Ниндидер яңа бер әйбер белән танышкан вакытта син әле нәрсәнең дөрес, ә нәрсәнең дөрес түгел икәнен белмисең дә, аңламыйсың да. Аңлы рәвештә яки үзе ялгышып, башкаларны ялгыш юлдан алып баручылардан безне Аллаһы Тәгалә Үзе араласын!

Бүгенге көндә белем алам дигән кешегә мөмкинлекләр бик күп. Республикабызда берничә мәдрәсә эшләп килә. Һәм бер Казанда гына да түгел. Кешеләр белем алу өчен үз өйләреннән меңнәрчә чакрым ераклыкка китеп, аның өчен күп вакытларын сарыф иткән заманнар да бар иде. Хәзерге вакытта өеңнән чыкмый гына лекцияләр, вәгазьләр тыңларга, өйрәтүче видеолар карарга мөмкин. Шунысын кабатлап әйтәсе килә, үзегез тыңлаган, караганыгызның чыганагын тикшерегез, яхшы материал булса, якыннарыгызга тәкъдим итегез. Әгәр дә үзегез белмәсәгез, белгән кешеләрдән сорагыз. Барысын да белеп бетерү мөмкин түгел. Сораганның оятлы юк. Белмәү гаеп түгел, ә белергә теләмәү гаеп.

Мәчетләр каршында дин нигезләре, Коръәнне өйрәнү буенча курслар оештырыла. Балалар өчен генә түгел, өлкән яшьтәгеләр өчен дә. Белем алырга беркайчан да соң түгел. Кайбер мәчетләрдә төрле темаларга лекцияләр укыла. Шуларны барып тыңлагыз, ишеткәннәрегез турында уйланыгыз. Аллаһның гыйлем дигән нигъмәтенә омтылыгыз. Гыйлемле, шуның нәтиҗәсендә нык иманлы булырга тырышыгыз.

وَمِنَ النَّاسِ وَالدَّوَابِّ وَالْأَنْعَامِ مُخْتَلِفٌ أَلْوَانُهُ كَذَٰلِكَ إِنَّمَا يَخْشَى اللَّهَ مِنْ عِبَادِهِ الْعُلَمَاءُ إِنَّ اللَّهَ عَزِيزٌ غَفُورٌ

"Шулай ук кешеләрне, хайваннарны вә кошларны төрле төстә халык кылдык. Аллаһтан куркырлар Аның хөкемнәрен белгән галим кешеләр. Аллаһ җиңүче вә мөэминнәрне ярлыкаучыдыр" (Коръән, 35:28).

Ләкин, белемнәрне алу гына җитми. Аларны тормышта кулланырга, аларга таянып яшәргә өйрәнү күпкә кыенрак. Мөхәммәд пәйгамбәр (салләллаһу галәйһи вәссәлам) болай дигән: "Кеше үз белемнәре буенча яшәргә өйрәнми торып, гыйлемле кеше булып санала алмый".

Икенче бер хәдисендә Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи вәссәлам) болай ди: "Белемнәрне мактану, надан кешеләр белән бәхәстә куллану яки үзегезгә кемнеңдер игътибарын җәлеп итәр өчен алмагыз. Кем шулай эшли - тәмугта янар".

Белем алу - бары тик мәктәп партасы, кырыс укытучы һәм камчы белән укыту, дип тә уйларга кирәкми. Белемне без үку йортларында гына алмыйбыз. Мәчеттәге вәгазьләрдән, мөселман кардәшләребез, мөселман илләреннән килгән кунаклар белән аралашулардан да белемгә байыйбыз. Белем алу - авырлык түгел. Аллаһның безгә биргән олуг нигъмәте ул. Исламны танып белү өчен биргән нигъмәте. Үз-үзебезне танып белү өчен биргән нигъмәте.

Татарстан Республикасы мөфтие
Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН

КОРЪӘННЕҢ БЕР КИТАП ИТЕП ЯЗЫЛУ ТАРИХЫ

СОРАУ. *Ни өчен Коръәни-Кәрим Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) вакытында түгел, ә тәкъва хәлифәләр вакытында бер китап булып язылган?*

ҖАВАП. Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) бу дөньядагы тормышы тәмам булу белән Коръәни-Кәрим иңдерелү дә тәмам була. Аятьләр аерым сүрәләргә җыелып, аларның чиратлыгы билгеләнә. Ә Коръәннең аерым бер китап булып дөньяга чыгуы - тәкъва хәлифәләр җилкәсенә төшкән бөек һәм әһәмиятле зур эш була. Аллаһның рәсүле (с.г.в.): "Минем өммәтемнең галимнәре исраилләргә (борынгы яһүдиләргә) җибәрелгән пәйгамбәрләр кебек", - дигән.

Алардан башка тагын кем шулкадәр дә җаваплы бу күрсәтмәне чынга ашыруны җитәкләргә сәләтле иде? Пәйгамбәрнең (с.г.в.) бу сүзләреннән илһам алып, алар бу эшкә тотына да. Беренче тәкъва хәлифә Әбу Бәкер (р.г.) вакытында ук бу эш тормышка ашырыла: Коръән аерым бер китап булып җыела. Әбу Бәкер (р.г.) хакимияте вакытында Ямамда барган сугыш күп кенә коръәнхафизларның тормышын өзә һәм Коръәнне аерым бер китап итеп җыю турындагы карарга килүне тизләтә.

Госман (р.г.) хәлифә вакытында Коръәннең җиде нөсхәсе язылa һәм төрле шәһәрләргә - Мәккәгә, Димәшкъка, Басрага, Бәхрәйнгә, Куфәгә, Йәмәнгә җибәрелә. Коръәннең бер нөсхәсе Мәдинәдә калдырыла.

Сәхабәләрнең киемдә һәм ризык куллануда тыйнаклыгы

Аллаһ нигъмәтләрен исраф итүнең бүгенге көндәге кебек киң масштаблары кешелек тарихында булмагандыр, мөгаен, без барыбыз да моңа шаһитбыз һәм бу исраф итүдә, кызганычка, үзебез дә актив катнашабыз. Кешеләр су, ризык, кием һәм энергия ресурслары тотылуның елдан-ел яңа рекордларын куя. Кешеләрнең аларга булган ихтыяҗлары елдан-ел арта гына бара. Әгәр дә Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) тәһарәт алган вакытта бер литр суны җиткергән булса (Әнәс бине Малик тапшыруы буенча, Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) ике ратель сыешлы савыт белән тәһарәт алган), хәзерге мөселманнар бу гамәлгә өч, биш, ә кайвакыт ун литр су тоталар.

АЛЛАҺ яратканнары арасында иң яхшысы - Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) бервакытта да туйганчы ашамаса, без, эш арасында тамак ялгап алулар һәм чәй эчүләрне исәпләмәгәндә, көн саен өч тапкыр тукланабыз. Без Аллаһ Рәсүленең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) сөннәтен үтәп бару турында күп сөйлибез, тик Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) һәм аның сәхабәләренең нинди кием киеп йөрүләрен, аларның бар киемнәре нәрсәләрдән торганын еш кына онытып җибәрәбез. Еш кына байлыкларын чамасыз тотучы бай кешеләрнең куллану дәрәҗәсенә җитәргә тырышабыз, тәүлегенә 24 сәгать буе моны телевидение дә, интернет та рекламалый, без хәзер Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) һәм аның сәхабәләре кебек өлге булырдай кешеләрнең куллану дәрәҗәсе нинди булуын искә төшермәскә тырышабыз.

Без нәрсәгә омтылабыз соң? Бу дөнья нигъмәтләренә, бу дөньяның тышкы ялтыравыкларынамы? Аларның бакыйлык өчен нинди әһәмиятләре бар соң? Безгә Аллаһы Тәгаләнең "Әхкаф (Комлык)" сүрәсенең 12 нче аятендә әйткән (ул алга таба китерелләчәк) дәһшәтле кисәтүе җитмимени? Ә бит сәхабәләр аны бик еш әйтә торган булганнар. Аллаһы Тәгаләнең:

"Тиешсез урынга малны исраф итүчеләр, әлбәттә, шайтан кардәшләредер!" (17/27), - дигән аяте безне бераз булса да кыенсындырмыймыни? Ә безгә ничек итеп шайтан кардәшләре түгел, ә Аллаһ Рәсүленең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) кардәшләре булырга? Бу юлда беренче адым булып Аллаһ Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) һәм аның сәхабәләренең бу дөнья нигъмәтләренә мөнәсәбәтләре нинди булуы турындагы белемнәргә ия булу тора. Аллаһ Рәсүленең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) бу дөнья нигъмәтләренә мөнәсәбәте белән танышу яхшы якка таба үзгәрүгә башлангыч нокта булып китсен. Шәхси куллануны чикләүдән башлап, без үзебезнең нәфесебезне авызлыклый, рухи камиллеккә ирешкән гүзәл кешеләргә рухи якынлаша алабыз. Ә бит без көн саен, алар белән бергә кубаруын сорап, Аллаһка ялварабыз! Аллаһы Тәгалә Изге Коръәндә болай ди:

"Ий гакыл ияләре, боларның хәлләреннән гыйбрәтләнегез" (59/2).

Әбу Бәкернең (р.г.) үлем түшәгендә ятканда Габдерахман бине Ауфка әйткән сүзләре

Габдерахман бине Ауф (р.г.) сөйли: "Мин Әбу Бәкер (р.г.) янына бардым. Ул үлем хәлендә иде. Мин сәлам биргәч, ул болай диде: "Мин сезне бу дөнья белән алган кебек итеп күрдем. Ә бу дөнья ул - фани, ул сезне белән алгач, Ардабильдән китерелгән йоннан эшләнгән гадәти ятакларыгыз сезгә инде чәнчә торган булып тоела башларлар, сез инде андый ятакларда йокларга теләми башларсыз, сезгә парча түшәкләр, ефәк пәрдәләр кирәк булыр. Ләкин, Аллаһ белән ант итәм, дөньявилык дәрьясында йөзгәнгә караганда, бер гаепсезгә сезнең башыгызны чабып өзүләре күпкә хәерлерәк".

Габдулла бине Гомәрнең бу дөнья нигъмәтләренә мөнәсәбәте

Гобәйдуллаһ бине Адий бине Гомәрнең ирекқә чыгарылган колы булган. Бервакыт, Гыйрактан кайткач, ул бине Гомәрне күрергә барган. Барып сәлам җиткергәч, аңа Гыйрактан алып килгән бүләге барлыгын әйткән. Бине Гомәр аннан: "Ул нинди бүләк?" - дип сораган. Гобәйдуллаһ: "Ул бүләк - җәвәриш", - дигән. Бине Гомәр: "Нинди җәвәриш?" - дип сораган. Гобәйдуллаһ: "Бу ашказаны эшчәнлеген яхшырта торган дару", - дип аңлаткан. Ә бине Гомәр аңа: "Мин инде менә кырык ел туйганчы ашамыйм, ни эшлим мин ул дару белән?" - дигән.

Хөзәйфә бине Яманның бу дөнья нигъмәтләренә мөнәсәбәте

Сәидә бине Сад бине Хөзәйфә Хөзәйфәнең (р.г.) менә бу сүзләрен сөйли: "Барыннан да бигрәк миңа, өйгә кайткач гаиләмнең, ашарга пешерер өчен өйдә бернәрсә дә юк, дип каршы алган көннәре ошый төшә. Чөнки мин бу вакытта Аллаһ Рәсүленең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) шундый сүзләрен искә төшерәм: "Аллаһы Тәгалә мөэминне бу дөнья нигъмәтләре белән мавыгуларыннан өйдәгеләр авыру кешене зарарлы ризыктан саклаганнан да ныграк саклый. Аллаһ мөэминнәрне проблемалардан ата кеше үз баласына бәрәкәт теләгәннән дә ныграк саклый".

Могтәбәр Гайшәгә Аллаһ Рәсүленең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) киңәше

Бервакыт, могтәбәр Гайшә елаган вакытта, Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) аның янында булган һәм: "Нигә елыйсың?" - дип сораган. Елавының сәбәбен ачыклагач, ул болай дигән: "Әгәр дә син башка дөньяда да минем белән бергә булырга телисең икән, сиңа бер мосафирга җитәрлек ризык җитсен. Байлар белән күп аралашма. Сакчыл бул, иске киемнәрне чыгарып ыргытма, аларны ямап, тегеп, рәткә китер".

Аллаһ Рәсүленең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) Әбу Җөхәйфәгә биргән киңәше

Әбу Җөхәйфә (р.г.) сөйли: "Мин симез ит шулпасын ашагач, Аллаһ Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) янына барган идем. Күп ашаганнан мине кикертә башлаган иде. Шунда Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) миңа: "Әбу Җөхәйфә! Бар, миннән читкәрәк китеп кикереп утыр! Бу дөньяда корсакларын ярылганчы тутырган кешеләр ахирәттә озак вакытлар ач торырлар", - диде". Шул вакыттан башлап үзенең вафатына кадәр Әбу Җөхәйфә туйганчы ашамаган. Әгәр дә ул иртән ашаса - кич, ә кич ашап ятса иртән тукланмаган.

Могтәбәр Гомәр Җәбир бине Габдулла сатып алганны сәер дип исәпләгән

Яхъя бине Сәед сөйли: "Бервакыт Гомәр Җәбир бине Габдулла белән очрашкан. Аның кулында дирһәм күргәч, ул аннан: "Син бу дирһәм белән нишләргә җыенасың?" - дип сораган. Ул: "Мин моңа өйдәгеләргә ит сатып алырга җыенам", - дип җавап биргән. Аннан соң Гомәр: "Алар синнән ни сорыйлар, син аларга шуларны гел сатып алып бирәсеңме? Ә сез менә шул аятьне кая куясыз.

"Кыямәт көнне кяферләр утка кучерелерләр вә әйтелер: "Сез дөнья тереклегендә Аллаһның күп нигъмәтләре белән файдаланып, әмма Аңа гыйбадәт кылмыйча бәгъзе яхшы эшләрегезнең савабын бетердегез, инде бүген хур, рисвай итүче газап белән җәза ителәсез, җир өстендә хаксыз тәкәбберләнгәнегез һәм чиктән чыгып бозыклык кылганыгыз өчен" ("Әхкаф (Комлык)", 46/20)".

Могтәбәр Гомәрнең Әбу Дардага язган хаты

Сәләмә бине Көлсем һәм Рәшид бине Сад тапшыралар: "Гомәр, Әбу Дарданың Хомс шәһәрендә үзенә башкаларныкыннан биегрәк йорт салуын белгәч, аңа хат юллаган. Хатында ул болай дип язган:

"Ий Әбу Дарда! Син үзеңә яңа йортлар төзисең, византиялеләр һәм фарсылар төзегән йортлар җитмәгәнмени? Ләкин бит сез, Аллаһ Рәсүленең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) сәхабәләре буларак, бар мөселман өммәтенә үрнәк булып торырга тиешсез. Бу хатны алу белән кичектергесез Хомстан кит һәм Шәмгә бар". Гомәр Әбу Дарданы Шәмгә җәза бирү өчен күчергән дип исәпләнелә.

Гомәрнең җирле әмирләргә киңәше

Габдулла әр-Руми сөйли: "Мин Өммә Талькка килгәч, аның йортының түбәсе бик тәбәнәк булганын күрдем һәм аңа болай дидем: "Ий Өммә Тальк! Синең өеңнең түбәсе нинди тәбәнәк!" Ул миңа: "Ий улым, Гомәр әл-Хаттаб (р.г.) җирле әмирләргә: "Биек йортлар төземәгез, сезнең өчен иң начар көн сез биек йорт төзи башлаган көн булыр", - дип боерды".

Габдулла бине Гомәрнең яңа кием сатып алган улына киңәшләре

Мәймүн (р.г.) сөйли: Габдулла бине Гомәрнең улларының берсе үз әтисеннән изар (гарәпләрдәге өс киеме) сатып алдырткан. Бераз гына киеп йөргәннән соң, киеме ертылган да ул бу хакта әтисенә барып әйткән. Әтисе аңа: "Ертылган чабуын кисеп ташла да киеп йөр", - дигән. Үсмергә бу ошап бетмәгән. Күңеле төшкән улын күреп, бине Гомәр аңа әйткән: "Хәсрәт сиңа, Аллаһтан курык! Корсакларын тутыручы һәм Аллаһ биргәннәрнең барысын да аркасына төяп баручылар исемлегендә булма!"

Әбу Бәкернең яңа кием кигән кызына әйткән сүзләре

Могтәбәр Гайшә сөйли: "Бервакыт мин яңа блузка кигән идем. Зур шатлыктан вакыты-вакыты белән гел аңа карый идем. Моны күргән Әбу Бәкер миңа: "Кая карыйсың? Мондый халәтеңдә Аллаһ сиңа игътибар итми", - диде. Ә мин аннан: "Ни өчен?" - дип сорадым. Ул: "Үз-үзенә мөкиббән киткән һәм дөнья нигъмәтләре белән мәшгуль булган кешеләргә Аллаһы Тәгалә, алар ул шөгыльләрен ташлаганчы, нәфрәт белән карый", - дип аңлатты. Аның бу сүзләреннән соң мин бу блузкамны салдым да хәер итеп бирдем. Шуннан соң Әбу Бәкер миңа: "Синең бу гамәлең ул гөнаһыңны йолыр дигән өметтәмен", - диде.

Ринат ГАББАСОВ

АРАГЫЗДА СӘЛАМ ТАРАТЫГЫЗ...

Мөхтәрәм мөселман кардәшләрем, әссәләәмү галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ!

Сәламне бирү үз эченә үзара дуслыкны, тынычлык таратуны алган. Моннан тыш сәламләү белән мөрәҗәгать итү исламда аерым кагыйдәләрне үтәүне таләп итә. Динебездә яшәеш рәвеше ислам дине тарафыннан канунлаштырылган һәм ул барлык мөселманнар өчен бер.

Мөселманга хас сыйфат - башка мөселман кешесе белән сәламләшү, сәлам бирү турында Коръәни-Кәримдә Аллаһы Тәгалә әйтә: "Әй, мөэминнәр! Үзегезнең өйләрегездән башка өйләргә рөхсәт алмыйча кермәгез һәм өйдә булган кешеләргә сәлам бирегез..." ("Нур" сүрәсе, 27 нче аять).

Мөселманнарның бер-берсе белән очрашып сәлам бирешүләре сөннәт гамәл булып санала. Ике як та бергәләп сәлам бирсә, сөннәт гамәл үтәлгән була. Бер тараф (як) соңга калса, аның эше сәлам алуга, сәлам кайтаруга, җавап бирүгә кайтып кала. Әлеге гамәл фарыз хөкеменә керә.

"Әл- Ислам" дигән сүз Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгаләнең күпсанлы исемнәреннән берсе. Сәлам бирү "Аллаһы Тәгалә исеме сезнең белән, сез Аллаһының саклавында" дигән сүзләрне аңлата. Мөхәммәд Пәйгамбәребез галәйһиссәлам дә сәламләшү хакында безгә күп нәсыйхәтләр калдырган. Бер хәдисендә Рәсүлебез әйткән: "Аллаһ исеме белән ант итәм, камил мөэмин булмыйча җәннәткә керә алмассыз. Ә мөэмин булмассыз бер-берегезне ярατканчыга кадәр. Әйтимме, сезне үзара дуслыкка, мәхәббәткә сәбәп булган бер сыйфатны - арагызда сәлам таратыгыз".

"Сәлам" сүзе "сәламәт" дигән сүздән алынган һәм сәлам бирүнең мәгънәсе дә "сезгә сәламәтлек телим, безнең тарафтан сезгә зарар булмас" дип әйтү. Һәрхәлдә, сәлам бирешү ул хәвеф вә хәтәрнең юклыгын аңлатудан һәм хәерлелекне белдерүдән гыйбарәт булган бер бик гүзәл мәгънәле гамәлдер.

Дин кардәшләрем, сәлам бирешүдә зур хикмәтләр бар. Чыннан да, бер кеше безгә елмаеп: "Әссәләәмү галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ", - дип сәлам бирсә, безнең күңелләребездә аңа карата җылылык, мәхәббәт туа. Без дә аңа шулай ук елмаеп: "Үә галәйкүм әссәлам үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ", - дип якты чырай белән җавап кайтарсак, аның күңелендә дә безгә карата ярату, җылылык барлыкка килер. Әгәр без шулай эшләсәк, бу эшләребез йөрәкләребезне начар сыйфатлардан пакьләр, җаннарыбызны уятыр, иманнарыбызны куәтләр. Телебез белән башкаларга хәер-дога кылу, сәламәтлек, тынычлык теләү - телебезнең юмартлыгыннан, күңелебез сафлыгыннан килгән матур сыйфаттыр.

Мөхтәрәм мөселман кардәшләр, сәламләшү мәсьәләсендә бездә зур кимчелекләр бар. Безнең арабызда сәламләшүгә бик җиңел, игътибарсыз караучылар да очрый. Кайсыларыбыз авырсынабыз, онытабыз, кайберәүләребез дәрәҗәләребез белән масаеп, тәкәбберләнеп башкаларга сәлам бирмибез. Ә бит: "Күңелендә бер тамчы тәкәбберлек булган бәндә җәннәткә кермәс", - ди Аллаһының Рәсүле.

Кардәшләрем, без бит мөселманнар, Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһиссәлам өммәтеннән, без аның сөннәтләрен шатланып үтәргә тиешбез. Хәзрәти Рәсүл Әкрам үзен ничек тоткан соң? Очраган кешегә үзе беренче сәлам биргән, күрешергә теләп кул суза торган булган... Ә без ничек? Теләгән кешегә сәлам бирәбез, теләмәгән, яратмаган кешеләр белән сәламләшмибез, икенче якка борылып узабыз, бу мөселманлык түгел инде. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам безгә үзебезне ничек тотарга куша соң? Бер хәдистә әйтелә: "Бер ир кеше Рәсүл галәйһиссәламнән: "Исламда иң яхшы эшләрдән ни санала?" - дип сораган. "Иң яхшысы - мохтаҗларны сыйлау һәм белгән вә белмәгән кешеләргә сәлам бирү", - дип җавап кайтарган Пәйгамбәребез галәйһиссәлам.

Сәлам хакында шундый сөенечле хәбәрләр булганга күрә сәламләшүгә бик игътибар итәргә кирәк. Сәлам бирер өчен көч-куәт, байлык-мал, зур белемле булу кирәкми, күңелебезнең эчкерсезлеге, пакьлеге генә кирәк. Аллаһының Рәсүле: "Сүздән элек сәлам булсын", - дигән.

Сәлам бирү - сөннәт гамәл, ә аңа җавап кайтару, сәлам алу - бу инде ваҗиб хөкеменә керә, дидек. Коръәни-Кәримдә: "...Сезгә сәлам бирелсә - яхшырак яки шулай ук җавап кайтарыгыз", - ди Аллаһ Раббыбыз. Шуның өчен без сәлам бирелгәнне ишетсәк, аңа җавап кайтарырга тиеш булабыз.

Сәламләшүнең тәртибенә килгән вакытта, кечеләр - олыларга, үтеп баручылар - туктап торучыларга, транспортта баручылар - җәяүлеләргә, азлар күпләргә башлап сәлам бирергә тиешле. Күп халык арасында бер кешенең сәламе бар кеше өчен дә җитә, әмма һәрберсе белән сәламләшсә тагын да яхшырак була. Намаз, Коръән, вәгазь укылган вакытта сәлам бирелмәс. Сәламләшкәндә елмаеп, кул бирешеп күрешергә кирәк, баш иярге кирәкми.

Кайчакта шундый очракка тап булабыз, мәҗлестә Коръән укыла, вәгазь сөйләнә һәм ризыклана торган вакытта соңга калып килгән кеше кул биреп күрешә башлый. Мондый гадәт мәҗлесне бизәми. Соңга калган кешегә тыныч кына кереп утыру хәерле яисә сәламне артык тавыш чыгармый гына биргән очракта, җәмәгатьтән бер кешенең җавап кайтаруы җитә.

Ир яисә хатын булсын, аңа сәламнең яхшысы: "Әссәләәмү галәйкүм", - дип әйтүдер. Әгәр дә "Әссәләәмү галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәтүһ", - дип сәламләсәк, бу тагын да тулырак һәм әҗерлерәк булачак.

Бер кеше аркылы җибәрелгән сәламгә дә: "Үә галәйкүм әссәләәм", - дип җавап бирергә кирәк. Кем дә булса берәр кешегә сәлам җибәрсә, ул сәламне иясенә тапшырырга кирәк, чөнки сәлам - бер әманәттер.

Ирләрнең - ирләргә, хатыннарның - хатын- кызларга, мәхрәмнәрнең мәхрәмнәргә сәлам бирүләре сөннәт булса да, кызганычка, бүгенге көндә әлеге гамәлебез артта калган. Аллаһының рәхмәте белән имамнарыбыз, мөгаллимнәребез үз мәхәлләләребездә, мәдрәсәләребездә шушы гамәлне халыкка җиткерә алсак, таратсак, бу Аллаһының Рәсүленең бер сөннәтен ныгыту, торгызу булыр иде, иншә Аллаһ. Өй әһелләребезне - әти-әниләрне, әби-бабайларны, ир-хатыннарны, бала-чагаларны да сәламләргә онытмыйк, чөнки сәлам бирешү гаиләдәге мәхәббәтне, тынычлыкны арттыра.

Әгәр ике мөселман бәндәсе бергә очрашканда кул бирешеп күрешсәләр, бер-берсеннән аерылганчы ук гөнаһлары ярлыканыр. Очрашканда гына түгел, ә саубуллашканда да сәламләшергә кирәк, моңа Пәйгамбәребез галәйһиссәлам сүзләре дәлил булып тора: "Әгәр бер кеше башкаларга кушылса - сәлам бирсен, әгәр аларны ташларга теләсә - сәлам бирсен, чөнки икенчесенең кирәклеге беренчесеннән ким түгел".

Мөселман кардәшләребез белән елмаеп сәламләшсәк - моны Коръәни-Кәрим һәм Пәйгамбәребез (с.г.в.) кушкан нәсыйхәтләрне истә тотып үтәсәк, Аллаһы Тәгалә безгә әҗер-савапларын бирер, арабызда җылылык, мәхәббәт хисләре артыр, иншә Аллаһ. Динебезнең хөрмәтле булуын, яшьләребезнең дингә тартылуларын теләсәк, сәламләшү кагыйдәләрен яхшы белеп һәм көндәлек тормышыбызда кулланыйк!

Аллаһы Тәгалә барчабызның күңелләренә динебезне чын мәхәббәт илә һәм дә булган күркәм гореф-гадәтләрне саклап, яратып тотарга, мөселман булып яшәргә насыйп әйләсен!

Әссәләәмү галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ!

Ильяс хәзрәт ҖИҺАНШИН,
Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә директоры

ХӘДИСЛӘР

"Сәлам" дигән сүз Аллаһы Тәгаләнең бер исеме. Бу сүзне Аллаһы Тәгалә җир йөзенә чыгарган иде, сез аны үз арагызда таратыгыз. Бер мөселман кешеләр яныннан узып бара, аларга сәлам бирә, һәм алар да аңа сәлам кайтаралар икән, шул сүз белән әлеге кеше олы дәрәҗә барлыгын аларның исенә төшергән булыр. Сәламне кайтармый калдырган булсалар да, алар урынына изге, пакь затлар сәламгә каршы җавап кайтарган булырлар иде.

Пәйгамбәр (с.г.в.) балалар яныннан узып бара торган булса, аларга сәлам бирә иде.

Кем сүзен сәлам бирүдән башлый, шул Аллаһы Тәгаләгә һәм Аның Рәсүленә иң якын кеше.

Атта баручы - җәяүлегә, җәяүле - утырып торучыга, азчылык күпчелеккә сәлам бирсен, сәлам кайтарганга - савап, кайтармаганга берни юк.

Сәламләшү күрешү белән тәмам.

Сүзләрен сәлам бирүдән башламаганнарга юл куймагыз.

Ике мөселман очрашкач та, Аллаһка хәмедләр әйтешеп, үзара кул биреп күрешсәләр һәм бер-берләренә ярлыкану теләсәләр, аларның һәр икесе ярлыканыр.

БУ ДӨНЬЯНЫ АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ БАРЛЫККА КИТЕРГӘН

Дөньяны Яралтучы булганлыкка җиләк-җимеш бакчасын мисал итеп китерик. Җиләк-җимеш бакчасының хуҗасы көннәрдән бер көнне иртән торгач, агачларының авып, сынып беткәнлеген күрсә, моны давыл яки башка төрле афәт нәтиҗәсе дип кабул итәчәк. Ләкин бакчадагы һәр өч агачның берсе генә ауган булса, бакчачы бу золымны җилгә түгел, акыллы затка, ягъни җинаятьчегә сылтаячак. Биш яки ун агачның сыны очраклы гына дип уйлый белмәгән кеше бу камил һәм төзек дөньяның очраклы рәвештә барлыкка килүенә ничек ышана икән? Ничек ул, бу дөнья үзен-үзе барлыкка китергән, дип саный ала икән?

Аллаһы Тәгаләнең барлыгына мантыйкый дәлил

Башлангыч А шарты: без монда хәзер яшибез.

Башлангыч Б шарты: моннан алда безнең бүгенге яшәешебезне тәэмин иткән бер-бер артлы төрле вакыйгалар булган.

Без монда хәзер яшибез икән, элек бер-бер артлы булган төрле вакыйгалар башлам булып тора. Бу вакыйгаларны берәү чиксез дәвам итә дип саный икән, чиксезлек ахырга якынлашкан дип раславы була, ә бу мантыйкка каршы килә. Бу: "Машина көпчәкләре чиксез күп тапкыр әйләнгәч кенә тиешле җиргә барып җитә", - дигән һәм килеп җитүен хәбәр иткән кеше сөйләменә охшый. Аңлашыла ки, көпчәкләрнең чиксез күп тапкыр әйләнүе генә тиешле җиргә барып җитү өчен шарт була алмый.

Дөньяның башлангычы һәм аны башланырга этәргән вакыйгалар булган икән, аларны Барлыкка китерүче дә булырга тиеш. Башлангычы булу һәм барлыкка китерелү - бер үк нәрсә ул. Иҗат итә - димәк барлыкка китерә, башлангычы булган һәр нәрсә барлыкка китерелергә тиеш.

Аллаһы Тәгаләдән башка һәр нәрсә Аның тарафыннан яралтылган һәм "дөнья" дип атала.

Аллаһы Тәгалә тарафыннан барлыкка китерелгән дөнья гарәп телендә "әл-галәм" термины белән йөртелә. Бу термин "әл-галәмәт" ("нәрсәгә дә булса күрсәтү") сүзеннән килеп чыккан.

Дөнья (әл-галәм) үзе Барлыкка китерүчесе булуын ап-ачык исбатлый.

"Ислам турында сөйләшик" энциклопедиясеннән

МӨБАРӘК КИЧӘЛӘР

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам үзенең бер хәдисендә болай ди: "Рәҗәп - Аллаһның ае, шәгъбан - минем аем, рамазан - өммәтем ае". Рәҗәп һәм шәгъбан - рамазан ае турында алдан хәбәр бирә торган, рамазанга әзерләнә торган айлар. Бу айларда без игътибар итәргә, гамәл-гыйбадәттә үткәрергә тиешле көннәр бар.

Бәрәкәтле никах кичәсе

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәлам рәҗәп аеның беренче җомгасына каршы кичтә (ул быел 1 нче майдан 2 сенә каршы кичкә туры килде) уяу булырга киңәш иткән. Күп гасырлар дәвамында мөселманнар бу кичәгә зур әһәмият бирәләр. Сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткән: "Биш кичәдә Аллаһы Тәгалә үз колларының үтенечләрен кабул кылыр: Рәгаиб, Бәраәт, Җомга киче, Рамазан һәм Корбан гаетенә каршы кичәләр".

Рагаиб кичәсе - Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәламнең әтисе Габдуллаһ белән әнисе Әминәнең никахлашкан көннәре. Шушы никах нәтиҗәсендә Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам дөньяга килгән. Пәйгамбәребезнең әтисе - улы туганчы, әнисе улына алты яшь вакытта вафат булалар. Мөхәммәд (с.г.в.) ятим кала. Әмма шушы Габдуллаһ белән Әминәнең саф җаннар, изге күңелле, хәрамга катышмаган яхшы кешеләр булганы өчен Аллаһы Тәгалә, изге бала биреп, дөньяны сөендерә.

Могҗизалы сәфәр төне

Рәҗәп аеның 26 сыннан 27 сенә каршы киче - Мигъраҗ кичәсе. Ул быел 25 нче майдан 26 сына каршы төнгә туры килә. Мигъраҗ - күккә ашу дигәнне аңлата. Бу кичтә Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вәссәламнең тормышында могҗиза була - ул Аллаһның кодрәте белән гаҗәеп бер сәфәр кыла.

Риваятьләр буенча, Рәсүлебез Мәккәи Мөкәррәмә шәһәрендәге Хәрам мәчете, ягъни Кәгъбәтулла янында йоклап яткан вакытта аның янына Боракка (яшен тизлегендә оча торган хайван дигән мәгънәдә) атланып Җәбраил фәрештә килә. Пәйгамбәребез (с.г.в.). Борак белән яшен тизлегендә Хәрам мәчетеннән Кодүс шәһәрендәге (Иерусалим) Әл-Әкъса мәчетенә күчә. Шунда Аллаһның Рәсүле, башка пәйгамбәрләргә имам булып, алгы сафта намаз укый. Соңрак аның алдына өч савыт китереп куялар. Аларның берсендә су, икенчесендә сөт, өченчесендә шәраб була. Аллаһның Рәсүле сөт салынган савытны сайлый. Җәбраил фәрештә моны күреп: "Әй, Мөхәммәд, син һәм синең өммәтең дөрес юлда. Исерткеч эчү - хәрам!" - ди. Аллаһның әмере буенча Пәйгамбәребез (с.г.в.) Җәбраил фәрештә белән күккә менә. Җиде кат күк аша үткәндә аларның һәр капусында ул үзенә кадәр Җир йөзенә килеп киткән пәйгамбәрләр белән очраша. Билгеле бер чиккә җиткәч, Рәсүлебез сәфәрен үзе генә дәвам итә. Ул анда җәннәт белән җәһәннәмне күрә. Аллаһы Тәгалә белән сөйләшү бәхетенә ирешә. Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгалә шушы кичәдә Пәйгамбәребезгә (с.г.в.) өч бүләк тапшыра:

- биш вакыт намаз фарыз кылына;
- "Бәкара" сүрәсенең ахыргы аятьләре (285-286 нчы аятьләр) тапшырыла;
- Пәйгамбәребезгә (с.г.в.) Кыямәт көнендә өммәтен яклау хокукы бирелә.

Бәраәт кичәсе

Шәгъбан аеның 15 нче көне елның иң олуг көннәреннән санала. Быел Бәраәт кичәсе июнь аеның 12 сеннән 13 енә каршы кичәнә туры килә. Ислам тарихындагы иң мөһим вакыйгаларның берсе "Тәхвилүл кыйбла", ягъни кыйбланың үзгәртелүе нәкъ менә шушы көнне була. Мәдинәи Мөнәвварәнең Бәни Сәләмә мәчетендә Рәсүлуллаһ (с.г.в.) өйлә намазы фарызының ике рәкәгатен укыганда аңа вәхи иңә, намазда торган хәлендә ул Кәгъбә тарафына борыла. Моны күргән сәхабәләр дә аңа ияреп, намазны дәвам итәләр.

Бу кичәдә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәт вә мәгъфирәте (гафу итү) Җир йөзенә таралып тора, бер ел эчендә булачак эшләр хакында хөкем кылына, әҗәл вә гомерләр билгеләнә вә кылынган гамәлләрнең сәхифәләре Аллаһы Тәгаләнең хозурына күтәрелеп күрсәтелә. Галимнәр, бу кичәне гафләттә (ваемсыз), гыйбадәтсез үткәргән кешеләр нинди зур өстенлектән мәхрүм булганнарын белсәләр, үкенү күз яшьләрен түгүдән туктый алмаслар иде, дип әйтәләр. Бәраәт көнен - уразада, төнен гыйбадәттә үткәрү, өч тапкыр "Йәсин" сүрәсен уку киңәш ителә.

АЛЛАҺНЫҢ ТӘҮБӘ КАПКАЛАРЫ ҺӘРВАКЫТ АЧЫК

Пәйгамбәребез (с.г.в.) үзенең бер хәдисендә Бәни Исраил кавеменнән булган бер кеше турында риваять китерә: "Заманында бер бәндә туксан тугыз кешене үтерә һәм аның күңеленә шик керә: әгәр тәүбә итсәм, Аллаһ мине гафу итәр микән?

Бу сорауга җавап табу өчен ул гыйбадәтханәгә бара. Анда бер хөрмәтле кеше янына килә һәм аңа сорау бирә: "Мин туксан тугыз кешене үтердем. Әгәр тәүбә кылсам, Аллаһ мине гафу итәр микән?" Теге кеше: "Кит, мөртәт, ничек инде син, туксан тугыз кешене үтереп, Аллаһның ярлыкавын өмет итәсең?"- ди. Бу сүзләрне ишеткәч, җинаятьченең ачуы чыга һәм: "Ярар, син йөзенчесе буласың", - дип бу кешене дә үтерә. Ләкин аның күңеле тынычланмый, шиге арта гына бара. Берникадәр вакыттан соң бу гыйлемгә, хикмәткә ия булган бер кеше янына килә һәм аңа да шул ук сорауны бирә. Хикмәт иясе: "Әлбәттә, Аллаһ сине гафу итәчәк, чөнки Аллаһы Тәгаләнең тәүбә капкалары һәрвакыт ачык, ләкин белеп тор, син бу шәһәрдә җинаятьче булып танылдың. Шуңа күрә башка шәһәргә кит. Шунда тәүбә кылырсың, сиңа анда беркем дә комачауламаячак",- ди. Бу кеше хикмәт иясенең сүзләрен күңеленә сала һәм күрше шәһәргә юнәлә, ләкин ярты юлда вафат була. Җинаятьче янына ике төркем фәрештә төшә. Бер төркеме: "Бу кеше җәннәткә керә", - дип әйтсә, икенчесе: "Юк, ул җәһәннәм әһеле булачак", - ди. Шулай итеп, фәрештәләр бер-берләре белән бәхәсләшә башлый. Аллаһы Тәгалә Җәбраил фәрештәгә: "Алар янына бар, үлчәсеннәр, бу кеше кайсы якка якынрак: чыгып киткән шәһәргәме, әллә бара торган шәһәргәме?" - дип әмер бирә. Фәрештәләр үлчи һәм җинаятьченең тәүбә кылырга бара торган шәһәргә якынрак булуын ачыклый. Аллаһы Тәгалә бу кешене җәннәт әһеле итеп язып куярга куша" (Әбу Ләйс Сәмәрканди. Тәнбиһүл-гафилин).

Тире авыруларыннан һәм акылдан язудан саклану өчен укыла торган дога

Аллаһ Рәсүле (с.г.в.) бу авырулардан шушы доганы укырга киңәш итәр иде: "Аллаһүммә инни әгузү бикә мин-әль-бәрасый үә-ль-җөнәни үә-ль-җөдәми үә сәйиэ иль-әскам" (Аллаһым! Тире авыруларыннан һәм акылдан шашудан сиңа сыенам). (Риязу'с-Салихин, Х.1481).

"МАКСАТ" ЯШЬЛӘРНЕ БЕРЛӘШТЕРӘ

14-20 нче май көннәрендә Татарстанда яшьләр өчен VIII Халыкара "Максат" фестивале үтте. Әлеге фестиваль Мөселман яшьләре фестиваленең дәвамы булып тора. Фестивальдә Россия һәм төрле чит илләрдән 100 егет һәм кыз катнашты. Аны Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы, Татар Федераль милли-мәдәни автономиясе, ТР мөселманнары Диния нәзарәте, "Идел" яшьләр үзәге һәм ТР Президентының эчке сәясәт мәсьәләләре департаментының дини оешмалар белән элемтә идарәсе бергәләп оештырды.

Фестивальнең максаты - Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә яшәүче яшьләрне берләштерү, аларны максатчан итеп тәрбияләү, күптөрле заманча проектларны чынга ашыру, мөһим мәсьәләләрне бергә хәл итү өчен үзара эшлекле элемтәләрне җайга салу.

Фестивальнең Кол Шәриф мәчетендә уздырылган ачылышында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да катнашты. Ул яшьләр белән бергә башта өйлә намазын укыды, аннары Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисләрен искә төшереп, яшьләрне сәламләде. Шулай ук хәзрәт, бу чара тарихи бер очрашу да булсын дип, яшьләрне төрек каллиграфы Мөхсин Демирәл белән таныштырды. "Ул Госман хәлифәтенең соңгы каллиграфы Хәмид Айтачның укучысы. Бүгенге көндә нәзарәт тарафыннан Изге Коръәнне гарәп шрифтының "нәсх" стиле белән һәм каллиграфиянең барлык кануннарын саклап бастыру әзерләнә. Бу эшне Мөхсин Демирәл башкарды. Менә бүген ул безнең арада утыра", - диде мөфти.

Яшьләрне шулай ук Россия ислам институты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин сәламләде. "Аллаһы Тәгалә безне төрле халыклардан һәм кавемнәрдән кылган. Берләребез татар, икенчеләребез чечен һәм башкалар. Без, әлхәмдүлилләһ, мин - татар, дип яши алабыз. Бу фестивальнең үткәрелүе дә татар халкының югары дәрәҗәгә ия рухи мирасы, мәдәнияте, тәҗрибәсе белән танышу", - диде ул.

Чарада дин әһелләреннән тыш рәсми затлар да катнашты һәм мөселман яшьләренә үзләренең теләк-ниятләрен җиткерде.

Атна буе барган фестиваль кысаларында Россия яшьләре өчен әһәмиятле мәсьәләләрне тикшерүгә юнәлтелгән түгәрәк өстәлләр, семинарлар, лекцияләр, конкурс һәм гамәли дәресләр, галимнәр, эшмәкәрләр, сәясәтчеләр, дин әһелләре белән очрашу-әңгәмәләр, төрле экскурсияләр үткәрелде.

МАТУР БУЛЫГЫЗ, ШӘРИГАТЬ КАНУННАРЫН ГЫНА БОЗМАГЫЗ

Казанда "Islamic Clothes-Fashion" халыкара мөселман киеме фестивале узды. Көндез фестивальдә катнашучылар өчен "Заман дөнья индустриясендә мөселман һәм милли киемнәр" дип аталган түгәрәк өстәл үткәрелде. Фестиваль "Пирамида" мәдәни-күңел ачу комплексында дизайнерларның мөселман киемнәре коллекцияләрен күрсәтү белән тәмамланды. Жюри хөкеменә Казан, Чаллы, Уфа, Мәскәү, Екатеринбург, Первоуральск, Нефтекамск, Курган өлкәсе, Чечня Республикасы һәм Төркия дизайнерлары үз эшләрен тәкъдим итте.

Чарада Иран Ислам Республикасының Казандагы генераль консулы Рәсүл Шаян, Татарстан мөфтие урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, ТР Дәүләт Советы депутаты, Бөтендөнья татар конгрессының Казан бүлеге җитәкчесе Фәрит Мифтахов, "ТАИФ" ҖЧҖ генераль директоры Руслан Гыйззәтуллин, Россия һәм Татарстан Мөслимәләре берлеге рәисе Наилә Җиһаншина һ.б. катнашты. Аны ТР мөселманнары Диния нәзарәте, "ТАИФ" ҖЧҖ, Россиянең мөселманнар дизайнерлары берлеге, Ислам мәдәниятенә, үсешенә, мәгарифенә ярдәм итү фонды оештырды.

– Мин Казанда беренче тапкыр мөселман киемнәре фестивале оештырылганны да хәтерлим. Татарстанда хәзер мөселман кызлары матур, зәвыклы киенә башлады. Минем бик күп илләрдә булганым бар. Иң чибәр, иң модалы һәм зәвыклы кызлар Татарстанда яши, - диде Иран консулы.

Фестивальдә Россиянең төрле шәһәрләреннән һәм чит илләрдән килгән дизайнерлар үзләренең коллекцияләрен күрсәтте. Аларның эшләрен мәртәбәле жюри бәяләде. Соңыннан Наилә Җиһаншина фестивальне оештыручыларга Рәхмәт хатлары тапшырды. Мөфти урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин Диния нәзарәте исеменнән Төркиядән килгән дизайнерга тегү машинасы бүләк итте. "Тагын да яхшырак тексеннәр, тырышсыннар, безнең хатын-кызларыбыз иң матурлардан булсыннар, шул ук вакытта шәригать кануннарын бозмасыннар", - диде ул.

Кием тегү буенча осталар "Иң яхшы рәсми костюм", "Иң яхшы татар костюмы", "Патшабикә күлмәге", "Иң яхшы туй күлмәге", "Иң яхшы яшьләр коллекциясе", "Стиль оригинальлеге", "Иң яхшы иҗади якын килү" һ.б номинацияләр буенча иҗади осталыкта көч сынашты. "Иң яхшы дизайнер-2014" исеменә исә "Зәңгәр томан" коллекциясе өчен Айсылу Кәлимуллина лаек булды.

Лилия ЛОКМАНОВА,
"Татар-информ"

ШАТЛЫКТА ДА, КАЙГЫДА ДА БЕРГӘ БУЛЫЙК!

Гаиләдәге гыйлем бәйрәме

Бу Гыйлем бәйрәме мәхәллә мөселманнары күңелендә иң беренчесе булганы өчен генә түгел, куанычлы нәтиҗәләре белән дә истә калыр, мөгаен. Быелгы уку елында Гаилә мәчете каршындагы курсларда өлкәннәр һәм балалар - барлыгы 180 гә якын кеше белем алды. Аларны 16 мөгаллим - югары белемле абыстайлар, хәзрәтләр, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе шәкертләре укытты. Уку елының уңышлы тәмамлануын алар зурдан кубып үткәрергә булды - махсус пешекчеләр яллап әзерләнгән табынга ул көнне 250 дән артык кеше җыелган иде.

Татарстан мөфтие урынбасары, Гаилә мәчетенең имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, шәкертләрне һәм мөгаллимнәрне Гыйлем бәйрәме белән котлап, аларга рәхмәт сүзләрен дә җиткерде. "Сез биргән белем ул - әманәт. Аллаһы Раббыбыз сездән разый булсын, савапларын язсын!- дип ул укытучыларга мөрәҗәгать итте. - Монда бар да сәдака, укыту өчен кирәк булган әсбаплар: тактадыр, партадыр, башкасыдыр - иганәчеләребез бүләге. Аларга да әҗер-саваплары язылсын". Аннары хәзрәт, Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисләренә нигезләп, гыйлем алуның һәр мөселман өчен мөһимлеге турында вәгазь сөйләде.

Соңыннан мәчет каршындагы курсларга йөргән барча шәкертләргә "Ислам нигезләре" гыйлеме буенча 260 сәгатьлек курслар үтүләре турындагы сертификат тапшырылды.

Бәйрәмгә бик күп кунаклар да чакырылган иде. Казан шәһәре башкарма комитетының телләрне үстерү һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек бүлеге җитәкчесе Ирек Арсланов та мәхәллә халкын бәйрәм белән котлады.

– Казанның 59 мәчетендә бүгенге көндә җомга намазлары укыла һәм дини эшчәнлек алып барыла икән бу - безнең өчен зур горурлык. Гаилә мәчете әле узган ел гына ачылса да, мәхәллә булып оешып, инде шәһәребезнең иң күренекле рухи үсеш үзәкләренең берсенә әверелде. Сезнең эшчәнлектән башка моны күз алдына да китереп булмый. Намазга кеше йөрмәсә, мәчетнең ни кадере булыр? - диде ул, хәзрәтләрнең югары дәрәҗәдә эшчәнлек алып баруларын ассызыклап.

Аннары балалар ел дәвамында бирелә алган белемнәрен күрсәттеләр, Коръән аятьләре укыдылар. Мөнәҗәтләр әйттеләр, кызыклы викторина сорауларына җаваплар бирделәр.

Бәйрәм тәм-томнардан сыгылып торган мул табын артында әле озак дәвам итте. Шәкертләр төркем-төркем булып истәлеккә фотога төште, мөгаллимнәр киләсе уку елына уй-ниятләре белән уртаклашты. Без исә Татарстан мөфтие урынбасары, Гаилә мәчете имам-хатыйбы **Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН**нан коллектив алдына куелган максатлар турында сораштык.

Мәчетебез районның "йөрәге"нә әверелсен, дибез

- Яшь кешеме ул, әби-бабаймы, әллә бала-чагамы - бирегә нәрсә эзләп килгән булса, шуны тапсын иде. Аллага шөкер, балага исем кушу, никах уку залы эшләп тора. Никах мәҗлесен әти-әниләре, туганнары белән килеп уздырырлык уңайлыклар тудырырга тырышабыз. Хәзерге яшьләр бер ел торалар да, холыкларыбыз туры килмәде, дип аерылышалар. Сәбәбе әти-әниләренең рөхсәтләрен алмыйча яши башлау. Шуңа күрә дәрәҗәле урында - түр башында әти-әниләре утырсын, дибез.

Без диннәр, гореф-гадәтләргә уңай караш булган дөньяви дәүләттә яшибез. Шуңа күрә дәгъват бүлеге булдырып, шушы бүлек дөньяви бәйрәмнәргә багышлап аерым чаралар уздырса, әле намазга басмаган, мәчеткә йөрергә ояла торган, нәрсәнедер дөрес эшләмәм, дөрес әйтмәм, диган кешеләр дә курыкмыйча, оялмыйча мәчетебезгә йөри башларлар, иншә Алла. Атна саен кичерәк чаралар булса, айга бер тапкыр кунаклар чакырып, вәгазь белән, дәгъват белән зуррак бәйрәмнәр үткәрергә диган теләк бар.

Гаилә ул балалардан башлана. Аллаһы Тәгалә разый булсын, без аларны һәрдаим кайгыртып торабыз. Менә хәзер дә архитекторлар белән сөйләшүләр бара, мәчет ишегалдында балалар мәйданчыгы ясарга ниятләдек. Турникларын, таучыкларын, урындыкларын куеп, юлларын ясасак, олылар да, яшьләр дә рәхәтләнеп мәчет янында ял итәрләр иде. Нинди милләттән, диннән булуларына карамастан, районыбыз халкы биредә рәхәтләнеп ял итәчәк, Алла теләсә.

Мәчеткә шатлык белән дә, кайгы белән дә киләләр. Кайгылы вакытларында да кардәшләребезгә ярдәм итәргә насыйп булсын иде. Үзем дә әти-әниемне җирләдем, беләм, ул чакта бик авыр була, нишләргә дә белмисең. Кайгылы вакытында мәчетебезгә керәләр икән, кәфенлекләре дә, ләхет такталары да, юа торган әби-бабайлары да, җеназа укучы мулласы да әзер булып торсын. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) бер хәдисендә, кайгылы вакытында бер кешегә ярдәм күрсәтсәк, Аллаһы Тәгалә аның теләгәнен үтәр, диелә.

Киләчәккә планнар бар инде ул, мин аларны куркып кына әйтәм. Без мәетләрне юу өчен тугызынчы катларга менгезәбез. Хәтта бастырып күтәрәбез, чөнки лифтлар да, баскыч мәйданчыклары да бәләкәй. Болай да кайгылы вакытта тагын шундый уңайсызлыклар өстәлә. Европада, гарәп илләрендә, Төркиядә әнә зур мәчетләр янында мәетләрне юа торган җеназаханәләр бар. Аллаһы Тәгалә ярдәмен салып, менә шуларын да булдырсак иде. Юып, кәфенләп, җеназасын укып, шушыннан, иншә Алла, мөселман зиратына озата торган булсак иде.

Әлхәмдүлилләһ, мәчеткә йөрүчеләр көннән-көн күбәя. Хәзерге вакытта җомгада ике зал тула, хатын-кызлар да үз залларын тутыра. Җәйгелеккә, рамазан аена кадәр залга сыймый калган кардәшләребез өчен тәзтүбәме, чатырлармы - нәрсәдер уйларга кирәк. Рамазан аенда мәчетебездә көн саен ифтар ашлары уздырырга ниятләп торабыз. Кардәшләребез инде ифтар ашын үткәрергә чиратка да языла башладылар, хәзрәт, миңа бер көнне калдырыгыз, ике гаиләгә бер көн калдырыгыз, дип мөрәҗәгать итәләр. Без моны бик хуплап, урын бирәбез, чөнки Пәйгамбәребезнең (с.г.в.), кем ураза тотучыны ашатса, аңа ураза тоткан савап булыр, дигән сүзе бар.

Табиблар никадәр генә саваплы димәсен, хәзерге заманда халык җәяү йөрми. Җомга көнне машиналар куярга урын юк. Шәһәр башлыклары белән уйлашып, мәчеткә йөрүчеләр өчен парковкалар булдырырга кирәк, дип уйлыйбыз.

Балаларны мәчеткә җәлеп итү максатыннан без мәктәпләр, балалар бакчалары, ишегалды клублары белән дә эшлибез. Хәзерге вакытта дус, бердәм мөгаллимнәр коллективы тупланды. Әмма бу эштә дә заманадан артта калырга ярамый. Диния нәзарәте тарафыннан расланган дәреслекләрне электрон телгә күчереп, шуларны да кулланырга Аллаһы Тәгалә ярдәм итсен иде. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар төркеме ачарга теләк бар, әти-әниләр дә бик сорый. Әмма сыйныф бүлмәләре җитми, кайсы почмакта ясарга дип баш ватабыз.

Мөселман кем ул дигәндә, озын сакаллы кыска ыштанлы, кулына автомат тоткан кешене күз алдына китерүчеләр бар, монысы өчен телевизорга "рәхмәт" инде. Мөселман ул - Раббыбыз Аллага буйсынучы, Аллаһ әйткәнне үтәүче кеше. Янәшәбездә яшәүче башка дин, башка милләт кешеләре мөселманны телевизор күрсәткән сюжетлар буенча түгел, ә безнең мәчетебезгә йөрүчеләргә карап танысыннар иде. Гаилә мәчете районыбызның "йөрәге" булып, шушында килгән һәр кеше үзен гаиләсенә кайткан шикелле хис итсен иде.

Сәхифәне
Нәүбәһар КӘБИРОВА әзерләде

"ДИН ӘҺЕЛЕ ГОМЕРЕ БУЕ ГЫЙЛЕМ АЛЫРГА ТИЕШ"

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм Россия мөселман яшьләре берлеге "Мөселман ышаныч телефоны"н эшләтеп җибәрде. (843) 202-4-202 номерын җыеп, шәригать буенча экспертка, мөселман психологы һәм юристка үзеңне борчыган сорауны бирергә мөмкин. "Мөселман ышаныч телефоны"на халык күбесенчә нинди сораулар белән мөрәҗәгать итә? Татарстанның баш казые ярдәмчесе Рөстәм хәзрәт ВӘЛИУЛЛИН белән шул сораудан башланган әңгәмәбез ислам диненә мөнәсәбәт, рухи үсеш, гомумән, яшәешебез турында килеп чыкты.

- Шалтыратулар бик күп, намазга барып килгән арада да йөзәр шалтырату кабул ителми калган була. Кайберләре озаклап сорау бирәләр дә башкаларга вакыт җитми. Сезгә чыгып булмый, дип зарланучылар да бар. Бөтен Татарстанга бер телефон бит ул! Техник яктан килгәндә, безнең күбрәк кешегә җавап бирергә мөмкинчелек бар, тик белгечләр җитми. Ник дисәң, бу бит гади генә аралашу түгел, су астындагы ташларны кузгатып, бик күп факторларны исәпкә ала торгач, дин ягыннан гади генә күренгән вакыйганың да хөкеме үзгәреп китә. Кайбер кешеләр бездә соңгы инстанция күрә. Олы яшьтәге кешеләр, минем яшисем килми, дип шалтырата. Аны аңларга, күңелендә уңай хис, өмет тудырырга тырышасың...

Өлкән яшьтәге кеше күп очракта балалары аркасында тынычлыгын югалта. Бервакыт мәчеткә килгән бер апа "балакаем" дип өзгәләнеп елый инде. Балакаегызга ничә яшь соң, дим. 45, ди. Шул яшькә җитеп, һаман әнисенең муенында утыра икән тегe. Ир башың белән әниеңнең пенсиясенә кредит рәсмиләштереп, аннан түләттер инде. Кызганычка, бу бит хәзер гадәти хәлгә әйләнеп бара. Ә табигатьтә ничек? Фәлән көнгә җиткәч, кошлар балаларын оядан бәреп төшерә. Очып китә алса - маладис, егылып төшсә - үзе гаепле. Ә безнең "кошлар" инде йоннары чаларган, үзләре әниләрен "оядан" куып чыгаралар. Бервакытны картлар йортыннан бер автобус әбиләрне мәчеткә ифтар ашына алып баргган идем. Барысының да балалары үлеп беткән микәнни, дип аптырадым башта. "Юк. Үзебез тинтәк, - ди арадан берсе. - Үз вакытында артык үчтекиләдек. Үсеп җиткәч әнә хатыны кирәк булды, без арттык". Вакытында ярдәмнән өзә белергә кирәк баланы. Мин бер вакыйганы беләм. Хәзер хәтеремдә түгел - әллә Чаллыда, әллә Түбән Камада бер атаның өч улы булган. Ата кәсеп иткән күрәмсең, балалар җитеш тормышта көчле булып үсеп киләләр икән. Боларның көчен дөрес юнәлдермәсә, харап булачакларын аңлый ата кеше. Балаларын җыеп ала да болай ди: "18 яшьтән сезгә минем өйдә йокларга урын һәм кичкырын кайтуызга бер тәлинкә аш. Калганын үзегез уйлагыз". Тиздән кесә акчасы бетәсен белсәң, син аны ничек тотасың? Әлбәттә, сабырлык белән. Олы улы уйлый, кымшана башлый, унсигезе тулгач, югалып калмый, әкренләп аякка баса. Икенчесенә, өченчесенә дә шул ук кагыйдә. Хәзер әнә этиләрен кулларында гына йөртмиләр! Шулай итмәсә, без бозылып киткән булыр идек, диләр.

- Хәзрәт, ә яшьләр нинди сорау белән шалтырата?

- Күбесенчә җавапсыз мәхәббәттән бәргәләнеп, яшисе килми, дип шалтыраталар. Кеше ул вакытта артык хисле була, илһамланган шагыйрь кебек әллә нишли. Кеше хәлен белмәгән кеше булсам, бу акылдан язгандыр, дип уйлар идем. Андыйларга болай дип аңлатам: бердән, мәхәббәтең төшкән кеше аңа лаек булырга тиеш. Икенчедән, чиксез мәхәббәткә - гашыйк булуга Аллаһы Тәгалә генә лаек (гәрчә бездә ул сүзне кешегә карата кулланалар). Гыйшык белән бер мәхлукны яратсаң һәлак буласың. Нигә? Чөнки аңа кирәк дәрәҗәдән артык ярату сәбәпле ул сиңа лаеклы җавап кайтара алмый. Ә менә кеше Аллаһны, дөньяви мәшәкатьләрне дә сизмичә, үзенең, әйтик, хәрабә йортта яшәгәнен дә күрмичә, шулкадәр нык яратса, Ул бу дөньяда булмаса, теге дөньяда хакын

кайтара (әле бу дөньяда да яхшы йортка күчерергә мөмкин).

- Кешегә карата булган андый хистән ничек арынырга?

- Ураза тотарга, энергия бирә торган ризыкны азрак ашарга, күбрәк су эчәргә кирәк. Бу тәҗрибәдән чыккан гына җавап, хәдискә таянып әйтүем түгел. Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез (с.г.в.) аша тормышта безгә бәла китерә торган әйберләрдән котылу юлын күрсәткән. Ул (с.г.в.) балаларын да, хатыннарын, дусларын, туганнарын да яраткан. Әмма Аллаһы Тәгаләгә гыйшкын башка беркемне ярату белән дә чагыштырырлык булмаган. Аллаһ рәсүле: "Котылмас, уңышка ирешмәс шул, кемнең күңелендә әти-әнисенә, балаларына һәм туганнарына Пәйгамбәргә (с.г.в.) караганда хисе якынрак булса; ул югалту кичерә", - ди. Ул Рәсүлебезне менә нәрсә белән сөендерә! Ә кеше нигә югалту кичерә соң? Ничек инде әтиәниең, балаларыңа караганда Пәйгамбәрне (с.г.в.) ныграк яратырга мөмкин? Чөнки Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) Аллаһы Тәгаләгә гыйшкы көчле булган һәм ул (с.г.в.) безне әти-әниебезне, балаларыбызны яратырга, хисебезне дөрес өлешләргә бүләргә өйрәтте.

- Моны акыл белән аңлап була, ә күңелгә ничек салырга?

- Акылың күңелеңне җиңә алмый икән, янә ураза тот. Күңелең акыл артыннан барып җитә алмый икән, намаз укы. Иртәнге, төшке, кичке ашны ашамаган кеше белән нәрсә була? Гастрит, ашказаны җәрәхәте, яман шеш, үлеп китәргә дә мөмкин. Җанның да "ашказаны" бар, аңа да ризык кирәк. Күп кешенең җаны җитлекмичә, җиде яшендә кала. Җиде яшьлек сабыйның, физик яктан хәтта иң зәгыйфенең дә, иптәшләре арасында тигезлекне саклар өчен рухи көче җитә. Җиде яшьтә кеше физик яктан камилләшә башлый, ә җан шул урында кала. Менә ни өчен Пәйгамбәребез (с.г.в.) җиде яшьтә намазга басарга куша. Кайчакта аптырап китәсең - әңгәмәдәшеңә 40-50 яшь, ә җаны җиде яшьтәге баланыкы. Рухи үсеш өчен Аллаһ безгә биш вакыт намаз биргән. Бар шундыйлар да: үзе утыз яшендә, җаны алтмышта. Димәк, сабый чактан ук намаз укый...

- Күбрәк мәхәббәт турында шалтыраталар, димәк...

- Хис турында дияр идем. Тормышына нәфрәтләнеп шалтыратучылар да байтак. Бирeдә сүз, мин дөрес яшәдем, дип санаган, ләкин дөрес яшәмәгән кешеләр турында бара. Аның фикеренчә, гаеп хатында, балаларда, әти-әнидә, җитәкчедә, президентта - барысында да! Ул гына гаепсез! Монда җайлап кына рухи бөлгенлектән чыгу юлын күрсәтәсең инде.

- "Ышаныч телефоны"на мөселманнар гына мөрәҗәгать итәме?

- Төрле кеше бар. Беркөнне бер христиан шалтыратты, бездә кайчан ислам банкы ачыла, дип сорый. Нәрсәгә кирәк ул сезгә, дим. Гайсә пәйгамбәр безнең тормышыбызда яшәсә, мөселманнарның икътисад системасы - бүгенге көн өчен иң кулае, дигән булыр иде, ди. Бик укымышлы кешегә охшаган...

- Хәзрәт, бу аралашуга үзегез ничек әзерләнәсез? Төрле сорауларга җавап бирергә туры килә бит.

- Монда бөтен потенциалыңны кулланасың инде. Дин әһелләре гомер буе гыйлем алырга, шәхси үсештә булырга тиеш. Туктаса, ул шәригать канунарын бүгенге яшәешебездә куллана алмый башлый. Мисал өчен, әгәр кеше сиксәненче елдан бүгенге көнгә кадәр бернәрсә укымаса, безнең компьютерда эшләүне күреп шаккатыр иде. Туксанынчы елларда ислам галимнәре, элек ничек уктан ату, атта йөри белү кирәк булган, бүгенге мөселман машина йөртә, компьютер куллана белергә тиеш, дигән фәтва чыгарды (фәтвага таянып эшләсә - әҗерле була, үз теләге белән генә эшләсә - нәрсәгәдер ирешер өчен эшләгән була). Машина йөртергә тиеш, дигәнне, әлбәттә, җаны-тәне сау-сәламәт булган кешегә кагыла. Мәсәлән, күзе күрмәгән, колагы ишетмәгән кешегә машина йөртергә ярамый. Хәтта кешенең бер күзе генә күрмәсә дә, ул ераклыкякынлыкны аера алмый бит. Бер генә колагы ишетсә, тавышның каян килгәнен белми. Өч колак булса да - мәшәкать. Компьютерга бер күз белән генә дә карап утырырга була анысы. Һәр әгъзаны Аллаһ безгә бер хикмәт белән бүләк иткән. "Ул - Аллаһ колак, күзләр вә күңел бирде сезгә, ләкин сезнең шөкер иткәнегез бик аздыр", - диелә "Мөэминнәр" сүрәсендә (78 нче аять).

- Әңгәмәдәшегезне исламга килергә өндисезме?

- Ул мәсьәләдә бик сак булырга кирәк. Исламга хәзер күпләп киләләр, шөкер. Әмма шул яңа гына намазга басканнар арасында калганнарны тар фикерле, аңсыз дип санаучылар байтак. Бүгенге мөселманнарның хәле белән санлашмыйлар, дин исеменнән үз фәлсәфәләрен тарата башлыйлар. Алар бик актив, әмма диндә озак тормыйлар. Башкалардан таләп итәсең икән, иң әүвәл үзең шул нәтиҗәгә ирeш син. Гайбәттән, мал-дан яратудан арынмаган килеш нигә башкаларны тәнкыйтьлисең? Иң яратмаганым - этник мөселман дигән төшенчә. Ул сүзгә хәдистә дә, Коръәндә дә дәлил юк. Бу бит, ул мөселман гаиләсендә туган, ләкин мөселман түгел, дип әйтү. Әле яңа гына ислам белән таныша башлаган кеше, иң аз дигәндә, алтыҗиде буын әби-бабасы мөселман булган, ләкин намаз укымаучыны шулай дип атый. Иман китерү өчен Аллаһы Тәгаләгә һәм Аның Рәсүленә ышану җитә. Намаз укымаган мөселман гөнаһкяр була, әмма ул синең кашыңда гөнаһкяр түгел. Ул бит сиңа түгел, Аллаһ каршында үзенә зыян салды. Вәгазьли алсаң вәгазьлә, әмма иманына тимә син аның!

Ләкин бу - намаз укымаган кешеләрне яклап әйтелгән сүз түгел. Мин аларны тәнкыйтьлим. Юкса, намаз укыр өчен хәзер бөтен шартлар да бар. Безнең мөселманнар намаз укымаулары белән бик күпне югалта.

Әңгәмәдәш –
Нәүбәһар КӘБИРОВА

ХИҖАП КИМӘГӘН ХАТЫН-КЫЗНЫҢ НАМАЗЫ КАБУЛ БУЛАМЫ?

Бу сорауны безгә еш бирәләр. Хәнәфи мәзһәбе буенча, хатын-кызның бите, кул чугы һәм аяк табаннарыннан кала бөтен тәне һәм башындагы чәче капланган булу - намазның бер шарты. Әгәр дә хатын-кыз намаз вакытында башын капламый икән, аның намазы кабул булмый. Әгәр дә намаз вакытында гаурәтен капласа, ләкин башка вакытта хиҗаптан йөрмәсә, аның намазы кабул булыр, иншә Аллаһ. Намаздан тыш вакытта хиҗапсыз йөрүе намазның дөреслеген билгеләми. Киресенчә, даими рәвештә намаз кылуы аны хиҗап киюгә этәрер диган өмет бар. Коръәни-Кәримдә намазның кешене начарлыктан саклаучы һәм яхшылыкка өндәүче гамәл булуы турында әйтелә.

Әти-әнисеннән яшереп, ислам динен кабул иткән кыз әлегә хиҗаптан йөри һәм намаз укый алмый икән - бу зур гөнаһ буламы? Мөселман хатын-кызлары өчен хиҗап һәм намаз фарыз, шуңа күрә ул әлеге гамәлләрне тизрәк үти башларга тиеш. Әгәр дә туганнары каршы килә икән, ул моны алардан яшереп үтәсен.

Хиҗапка килгәндә, өйдә хиҗап кию мәҗбүри түгел, аны урамга чыкканда гына кияргә кирәк. Яңа гына ислам динен кабул иткән булуы аның бөтен гамәлләрне дә шунда ук үти алмавын гафу итә, ләкин ул аларны әкрен-әкрен үти башларга тиеш. Аллаһы Тәгалә колларына карата беркайчан да гаделсез булмаячак, Ул аның хәленә карап хөкем чыгарачак.

Сухайл ТАРМАХОМЕД,
танылган ислам галиме

ГАДИ МӨСЕЛМАННЫҢ ЙӨРӘГЕ КҮТӘРӘ АЛМАСЛЫК КУРКЫНЫЧ БАРЛЫККА КИЛДЕ

Ибн әл-Җәүзи (508-597 х/ 1115-1201м) "Сәйд әл-Хатыр" китабында болай диган: Гади мөселманнар йөрәге күтәрә алмаслык зур куркыныч барлыкка килде. Мәсәлән, Аллаһы Тәгалә Гарешкә тиеп утыра яисә Аллаһы Тәгалә Асылы Гареш зурлыгында яки дүрт бармакка зуррак диган фикерне әйтеп, бер төркем алар йөрәгенә тәшбиһ, ягъни фикер салды. Һәм гади кешеләр үз шәехләреннән бу сүзләрне ишетеп, Аллаһы Тәгалә урынын алмаштырганда һәм дөнья күгенә төшкәндә Гареш буш кала дип уйлыйлар. Аларны тәнзиһкә (Аллаһның берни белән дә чагыштыргысыз булуы) өндәгәндә: "Бу алай түгел, сезгә шулай тоелган гына хәдиснең туры мәгънәсен аңлап ышанырга кирәк, ләкин күз алдына китермәскә", - диләр. Ләкин гади кешеләргә бу кыен, һәм моңа ике сәбәп бар.

Беренчесе: кешеләр бары тик матди чынбарлыкны аңлый.

Икенчесе: алар бу мәгълүматны үзләреннән дә надан булган шәехләрдән ишетә.

Моны башкаларга җиткергән кеше - үзеннән-үзе куркыныч кеше. Бер кешенең, ниндидер галимнең тәнзиһ гакыйдәсен аңлатуын тыңлап: "Аллаһы Тәгалә белән ант итәм, булдыра алсам, мин аны үтерер идем", - дип әйтүе турында ишеткәнем бар.

Нинди гыйбрәтле хикәя! Нәфесеңне тыя белмәү һәлакәткә алып бара ала. Без вәгъдә иткәнебезне аңлаттык, эшне озакка сузарга җыенмыйбыз. Без биргән гомуми күрсәтмәләр җитәрлек. Без, диндар кешеләрнең йөрәкләренә үтеп керер өчен, бөек галимнәрнең сүзләрен искә төшерү җитәр дип исәплибез. Мин Аллаһы Тәгаләдән бу хезмәтнең файда китерүен һәм аның аша кешеләрне туры юлга бастыруын үтенәм.

Сәид ФУДА
"Шәригать белеменең бүгенге торышының анализы" диган хезмәттән

ИСЕМЕҢ МАТУР, КЕМНӘР КУЙГАН?

Исемнәр өч төркемгә - хәләл, мәкруһ һәм хәрам исемнәргә бүленәләр. Хәләл исемнәргә килгәндә, галимнәр аны да өч дәрәҗәгә бүлгәннәр:

1)рәсүлләр, пәйгамбәрләр, изгеләр, әүлияләр исемнәре;

2)мәгънәсе яхшы булган исемнәр;

3)мәгънәсез исемнәр.

Аллаһы Тәгалә Җир йөзенә 124000 пәйгамбәр, 313 рәсүлне җибәргән. Безгә шуларның берничәсенең генә исеме билгеле:

Адәм (г.с.), Нух (г.с.), Шис (г.с.), Идрис (г.с.), Һуд (г.с.), Салих (г.с.), Ибраһим (г.с.), Лут (г.с.), Исмәгыйль (г.с.). Йосыф (г.с.), Муса (г.с.), Һарун (г.с.), Давыт (г.с.). Сөләйман (г.с.), Ильяс (г.с.), Әл-Ясагъ (г.с.), Юныс (г.с.), Зәкәрия (г.с.), Исхак (г.с.), Якуб (г.с.), Әюб (г.с.), Шогаеп (г.с.), Яхъя (г.с.), Гайсә (г.с.), Мөхәммәд (с.г.в.).

Әүлияләр Аллаһы Тәгаләгә якын булган кешеләр. Мисал өчен. Пәйгамбәребез (с.г.в.) хатыны Гайшә (р.г.), аның кызы Фатыйма (р.г.). Әбу Бәкер әс-Сыддик (р.г) Гомәр ибн әл-Хаттаб (р.г.), Госман (р.г), Гали (р.г.) һәм җәннәт белән шатландырылган сәхабәләр. Болар барысы да изге әүлияләрдән булып саналалар.

Ир-ат исемнәре

Айтирәк (борынгы төрки-татар) - ай кебек күркәм, нык тирәк

Айтуган (бор. төр.-т.) - ай кебек матур ир бала туган

Айшат (төр.-т.-фарсы) - ай кебек шатлык китерүче ир бала туган

Акбатыр (бор. төр.-т.) - яхшы күңелле батыр

Акбулат (төр.-т.-гарәп) - ак бәхетле һәм ныклы булат корыч

Акбүләк (төр.-т; йола исеме) - ак бүләк; әтисе бүләге (әтисе үлгәннән соң туган бүләк бала)

Акчура (бор. төр.-т.) - ак күңелле иптәш

Акъегет (төр.-т.) - намуслы егет

Акъяр (төр.-т.-ф.) - саф күңелле дус

Аллабиргән (г.-төр.-т.) - Аллаһ биргән угыл

Хатын-кыз исемнәре

Айсинә (т.-ф.) - яхшы күңелле

Айсолтан (төр.-т.-г.) - ай + солтан

Айсылу (бол.-т.) - ай кебек сылу

Айсөяр (т.; топонимик) - якътылыкны яратыр

Айшат (т.-ф.) - шатлык китерүче ай

Акбикә (төр.-т.) - күркәм бикә

Алия (г.) (Галия) - бөек, югары дәрәҗәле

Алкын (т.; неологизм) - тиз, җәһәт, кызу

Алмабикә (төр.-т.) - алма + бикә

Алмагөл (т.-ф.) - алма кебек алсу гөл

Гомәр Саттарның "Исемең матур, кемнәр куйган?" китабыннан

ИР-АТ ӨЧЕН ӨЧ ХАКЫЙКАТЬ

Укба бине Әмир (Аллаһ аңардан разый булса иде) Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) мондый сүзләрен тапшыра: "Бер ук өчен Аллаһ өч кешене оҗмахка кертер, аларның берсе - ул укны ясаучы, икенчесе - ул укны атучы һәм өченчесе - ул укны бирүче. Атта йөрегез һәм ук ату белән шөгыльләнегез! Шулай да уктан ату миңа атта йөрүгә караганда күңеллерәк кебек тоела. Күңел ачуларның барысыннан да бер файда да юк, ләкин алар арасында шул өчесеннән дә лаеклырак башкасы юк, алар: ир-атның атны тәрбияләп үстереп өйрәтүе, үз тормыш иптәшең белән шаяру һәм, атып бетергәч җыеп алып, ук ату. Бу - өч хакыйкать".

Кем дә кем, мин моны инде өйрәнеп бетердем дип, ук ату белән шөгыльләнүен ташласа, андый кеше - Аллаһ нигъмәтләренең берсеннән мәхрүм булган кеше. Яки алар турында: Ул Аллаһ нигъмәтләре өчен рәхмәтле була алмаган кеше, дип әйтергә була" (Әсхәбел Сөннән).

Islam-Today

Мәңгелек йортыбыз ни хәлдә?

Тормыш ыгы-зыгысы, мәшәкатьләр дип тормыйм, туган авылыма кайткач, мәңгелек йортыбызны барып карап киләм. Чөнки анда газиз әтием җирләнгән.

Үлеләр торыр терекләр догасы белән, исәннәр яшәр әрвахлар догасы белән, диелә бит хәдисләрдә. Без бер-беребезгә дә, үлгән кешегә дә дога кылырга тиеш. Аллаһы Тәгалә: "Әти-әниләрегезгә дога кылыгыз", - дигән. Ибраһим галәйһиссәламнең: "Үземне, әти-әниемне, бөтен мөселманнарны ярлыка, Раббым!" - дигән догасы бар. Шуларны укыйсың да Аллаһы Тәгаләнең күркәм исемнәре хакына үз теләгеңне әйтәсең һәм үлгән кешенең гөнаһларын ярлыкавын сорыйсың. Димәк, әрвахлар - безне, без аларны кайгыртабыз булып чыга... Газиз кешеңнең рухына белгәннәреңне укып ихластан дога кылгач, җаныңда ниндидер бушану барлыкка килә, чын-чынлап мәрхүмгә "сәлам күчтәнәче" җибәргән кебек, үзеңдә рәхәт бер тойгы кичерәсең.

... Зиратка якынлашкач, бу юлы иң беренче шул күзгә ташланды - каберстан яңа коймалар белән әйләндереп алынган. Авылдашларыбыз Наил Нотфулла улы Исмәгыйлев, Илдар Гыйльмулла улы Шәйдуллиннар үзләренең хәләл акчалары белән булышлык иткән икән бу эштә. Җирлек башлыгы Рәфкать Кәрим улы Кәримовка, авылдашларыма да рәхмәтлебез.

Зиратта берничә яңа кабер барлыкка килгән. Шунысы аяныч, кайберләре бу фани дөнья белән җир җимертеп эшләп йөргән чакларында хушлашканнар. Бергә бер сыйныфта укып, ике ел бер караватта йоклаган дустым Гөлсирә кабере. Безне чын дуслык бәйли иде. Айга өч-дүрт тапкыр, кайчан көненә берничә тапкыр да телефоннан сөйләшеп тордык. Соңгы мәртәбә үләренә өч ай кала сөйләштек. Күңеле күтәренке иде, авырганын да, хастаханәдә дәваланганын да белгертмәде. Аның кабере янында тын алырга да куркып басып тордым. Ике баласы - ятим, ире Миннихак тол калды. Белмибез шул үлем сәгате кемгә кайчан сугасын. Әҗәлне күз белән каш арасы кебек якын диләр бит. Дөнья куабыз, яшибез, җиткерәбез, киләчәккә әллә нинди планнар корабыз. Көннәрдән бер көнне дөнья белән алыш-бирешең өзелә һәм сине дә ак кәфенгә төреп бирегә китереп урнаштыралар... Кабер өстендәге агачларның шаулавы уйларымнан җиргә кайтара. Зират әһелләренә әйтелә торган кәлимәне искә төшерәм. "Әссәләәмү галәйкүм йә, әһлил кубур" (и, кабер әһелләре, сезгә сәлам булсын!) Менә әти кабере, күршебез Камилә апа кабере. Әтинең кабер өстен чия агачы баскан. Чардуганын киленебез Рәшидә Ганиуллина карап, буяп тора. Рәхмәт аңа.

Араларында чүп үләне баскан, ташландык хәлгә килгән "бик иске булмаган" каберләр дә бар. Онытылдылар микән? Якыннарының зиярәт кылырга вакытлары гына җитмиме? Дөнья чабудан тарта шул, дөнья...

Чардуган эченнән сирәкмирәк баш калкыткан чүп үләннәрен йолкып аткач, газизләремнең каберләре арасына утырып дога кылам. Укыганнарым барып ирешсен дә, рухлары шат булсын иде. "Төшкә дә кермисез, тыныч ятасыздыр... бездән риза-бәхил булыгыз", - дип күңелемнән генә сөйләнәсөйләнә чыгу ягына юнәләм. Зират капкасын ачып чыгу белән, беләм, кабат тормыш ыгы-зыгысы чорнап алачак. Бирегә күтәреп алып килгәнче, әле үз аякларымда килеш, әти каберенә озак еллар сукмакны суытмыйсы иде...

Фирая МИНГАЛИЕВА,
Мамадыш районы,
Уразбахты авылы

Гыйлем эстәүнең чиге юк

Гыйлем эстәүнең бүгенге көндә төрле юллары бар. Безнең Арча мөхтәсибәте, мәсәлән, дини бәйгеләр оештыра. Менә инде ничәнче ел мөгаллимәләр шурасы җитәкчесе Рая Ахун кызы һәркемне җәлеп итәрлек итеп ул бәйгеләрнең сценарийларын төзи. Ә мөхтәсибебез Раил хәзрәт Гыйлаҗев иганәчеләрен таба, бүләкләрен, табынын кайгырта.

Шундый бәйгеләрнең беренчесе Мәүлид бәйрәмендә мөгаллимәләр арасында узды. Мөгалимәләрнең эш-укыту планнары белән таныштыруы, дини дәресләр укыту методикасын аңлатулары, шәкертләре белән эшчәнлекләрен чагылдырган фотоальбом төзүләре, дәресләрне мавыктыргыч итеп уздырулары турында тәҗрибә уртаклашулары безнең өчен дә файдалы мәгълүмат иде.

Февраль аенда имам-хатыйблар бәйгесе дә бик үзенчәлекле үтте. Бәйгенең шарты гади генә күренсә дә, имамнардан зур җаваплылык таләп итте. Мәчеттә биш вакыт намазга азан әйтеләме, мәчетләрдә намаз укыламы, авыл халкы дингә тартыламы, җомга намазларына күпме мөселман йөри, җәйге лагерьлар оештырыламы - менә шул шартлар буенча урыннар билгеләнде ул бәйгедә.

Ә апрель аенда үткәрелгән балалар арасындагы бәйге мөгаллим-мөгаллимәләрнең эш нәтиҗәсен чагылдырды. Зур әзерлек белән катнашкач, әлбәттә инде, балалар да, мөгаллимәләр дә призлы урыннарга өметләнә. Шура әгъзалары, катнашучыларның һәрберсенең күкрәгенә саннар беркетеп, бәйгедә шул саннар белән генә эш итте. Раил хәзрәт бүләк тапшырганда катнашучы баланың исемен, кайсы мәчеттән икәнлеген, мөгаллимәсе кем булуын аның үзеннән әйттерде.

Бәйгедә җиңелүче юк, бар да җиңүче. Шулай да җиңүчеләр арасыннан урыннар билгеләнмичә калмый бит инде. Беренче урынны Шушмабаш белән Наласа мәчете шәкертләре алды. Икенче урынны Арча станциясе мәчете белән Яңы Кырлай мәчете, ә өченче урынны Иске Кырлай һәм Арча станциясе мәчетеннән килгән балалар алып китте.

Бәйгегә килгән балаларның күңеленә Аллаһы Тәгалә гыйлем орлыклары салган. Ул орлыклар шытып үсеп килә инде, җимешләре дә озак көттермәс, иншә Алла.

Тагын шуны да әйтәсем килә, Диния нәзарәте белгечләре безнең мөхтәсибәт белән һәрчак элемтәдә торалар. Уздырылган бәйгеләрдә катнашып, киңәшләрен бирәләр. Һәр айның икенче пәнҗешәмбесендә уздырыла торган имам-хатыйблар җыелышына кайтып, тәрбияви вәгазьләрен сөйләп, безнең күңелләребезне иман нуры белән баеталар.

Разидә ХӨСНЕТДИНОВА,
Арча районы,
Яңа Кишет авылы

Чишмә дә, безнең күңелләр дә сафланды

Узган ел сентябрь аенда газетабызда "Чишмәләр җыры тынмасын..." дип исемләнгән язмам басылып чыкты. Әлеге язмада Балык Бистәсе районының Юлсубино (Балтач) авылындагы иң тәмле сулы Закир бабай чишмәсенең ташландык, аяныч хәлдә булуын тасвирлаган идем.

Шул чишмәгә җан өрү макcатыннан, авылдашлар белән 1 нче майда чишмә янында җыйналдык. Билгеле, бу эшкә әзерлек бер ай алдан башланды. Интернеттагы авылыбыз төркемендә игълан-хәбәрне "элеп" куюга ук, берәү шалтыратып: "Нәзирә, мин дә бик теләп катнашам, синең телефоныңа акча күчердем инде" дигән күңелле хәбәр җиткерде. Гадәттә, мин мондый изге күңелле кешеләрне башкаларга үрнәк итеп куеп, исемнәрен халыкка танытам. "Исемемне әйтәсе дә, язасы да түгел, яшереп биргән садаканың әҗер-савабы күбрәк була", - дип кырт кисте ул. Әлеге шәһәр егетенең аягы җиңел булды, күрәмсең, чишмә янына килгән һәр кеше, һәр кайткан кунак: "Күрше, монысы миннән", - дип чишмә төзелешенә үз өлешен кертте. Ул көнне чишмә яны зур бер кырмыска оясын хәтерләтә иде. Берәү трактор белән агач төпләрен тарттырды, берәү аны утынга кисеп торды, калганнары йөгерә-йөгерә агач ботакларын учакка таба сөйрәп китте. Кемдер чишмә юлын чистартты, кемдер кибеткә материаллар алырга юл тотты... Ул арада казанда тәмле пылау пеште, самавырда чәй кайнады. Җыйнаулашып тәмле пылау ашадылар, чәй эчтеләр, Закир бабай чишмәсе, Шарлы елгасы белән бәйле балачак хатирәләрен яңарттылар. Чәй эчүчеләр янына бала-чага җыйналды. Алар - бер "зур эш"не тәмамлап, чишмә тәзәтергә килгән эшем кешеләре. "Зур эш" дигәнем - йорттан-йортка кереп йомырка җыю. Зур булмыйни! Иртәнге алтыдан торып, бөтен авылны әйләнеп чыгып кара әле син! Түбән очка төшеп җиткәндә зур, матур пакетың тулып, җирдән сөйрәлеп бара башлый...

Менә шундый "зур эш"ләр башкарып кайтканнан соң өлкәннәр белән берләттән чаба-чаба агач ботаклары ташыды, чүп-чар җыеп мәш килде бала-чага халкы. Нәкъ менә кайчандыр без мәш килгән кебек... Әйе, нәкъ утыз ел элек, нәкъ шушы чишмә янында безнең әти-әниләребез чишмә чистарта, ә без, бала-чагалар, аларга булышып, аяк арасында чуалып йөри идек. Әткәйләр инде мәрхүм, аларны без алыштырганбыз, Закир бабай чишмәсе генә "мин барысын да хәтерлим" дигәндәй ага да, ага...

Әйе, еллар уза, буыннар алышына, чишмә төзекләндерү, зират чистарту кебек мөһим, матур гадәтләр буыннан-буынга күчә. Бездән соң килгән буын да, һичшиксез, туган якның җырчы чишмәләренә, урманболыннарына игътибарын киметмәс, аларны күз карасыдый саклап, үзләреннән соңгы буынга да тапшырыр. Мондый чараларда катнашып, мондый матур күренешләрне күреп, күңел нечкәрә, сафлана, бетмәстөкәнмәс дөнья мәшәкатьләре онытыла. Әйтерсең, шау-шулы шәһәр, җитди киңәшмәләр, өстәл тулы кәгазь-документлар синең тормышыңда бөтенләй юк, булмаган, син шушы яшел чирәмле болын, челтерәп аккан чишмә янында гына гомер иткәнсең, яшәгәнсең. Нинди генә бөеклекләргә күтәрелсәң дә, нинди генә мөһим эшләр белән шөгыльләнсәң дә, туган нигез, туган як синең өчен изге җир булып калырга тиеш. Шул изге җиргә ешрак аяк баскан кеше генә Кеше булып кала, чистарына, сафлана...

Нәзирә ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА (МОСТАФИНА),
Казан

"КОРЪӘННЕ ЯТЛАГАНЧЫ БУ ДӨНЬЯНЫ БАШКАЧА КҮРӘ ИДЕМ"

Тулаем Коръәнне ятлап, аны йөрәгендә саклаган кеше "хафиз" дип атала. Бу һич тә мөмкин эш түгел, яисә бик тә авыр, дияргә ашыкмагыз. Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтә: "Дәреслектә, без сезгә Коръәнне иңдердек, һәм без аны үзебез саклаячакбыз" ("Хиҗер"сүрәсе, 9 нчы аять); "Аллаһы Тәгалә кешегә кулыннан килмәгәнне йөкләми" ("Бәкара" сүрәсе, 286 нчы аять).

Әңгәмәдәшем Махфузулла Казанга Таҗикстаннан килгән. Аңа 22 яшь. Өч ел рәттән коръәнхафизларның республика бәйгесендә җиңгән. Бүгенге көндә "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә тиләвәт (Коръәнне дөрес укырга өйрәтү) фәнен укыта.

- Махфузулла, син Коръәнне кайчан, ничек ятлый башладың?

- Балачактан ук, икенче сыйныфта укыганда 3 җүз белә идем инде. Әмма дә ләкин коръәнхафиз булырмын дип уйламаган идем. Ул вакытта мин остазга йөреп, әхлак, гакыйдә фәннәрен өйрәндем. Бервакыт укытучым авырып китте һәм мин шул вакытта Коръән белән җитди шөгыльләнә башладым. Кемнедер мәҗбүриләп Коръән ятлаталар икән, ул хафиз булып җитешмәячәк. Мин андый мисалларны да беләм. Үзең тырышканда, көч куйганда гына нәтиҗәгә ирешеп була.

Аллаһы Тәгалә бөтен кешегә дә Коръәнне ятлау сәләтен бирми. Бар кеше дә җиңел генә хафиз була алса, аның кадере кимер иде. Хафиз булу өчен бик күп сынауларны үтәргә кирәк. Шуларны үтсәң генә Аллаһ сиңа Коръәнне бирә. Гөнаһ гамәлләрне күп кылсаң, башың дөнья мәшәкатьләре белән тулган булса, Коръән истә калмый.

- Коръәнне өйрәнүнең махсус ысуллары бармы?

- Әлбәттә, төрле ысуллары бар аның. Кемдер бер битне бик күп тапкыр укый (100-300), ә мин берәр аятьләп өйрәнеп ятладым. Минемчә, болай ятлау җиңелрәк. Иртә белән ятлап, кич белән кабатласаң, ятлаганың озаграк истә тора. Ятладың да, калдырдың түгел, ә һәрдаим кабатлап торырга кирәк.

- Хафиз булганнан соң, көнгә ничә җүз кабатлау кирәк?

- Иң кимендә бер җүз. Моның аерым бер вакыты юк үзе, аны һәрвакыт кабатлау, ачып тору кирәк. 24 сәгать кешегә болай гына бирелмәгән.

- Коръән ятлаудан тыш хафизлар ниләр белән шөгыльләнәләр?

- Әлбәттә, алар гадәти кешеләр кебек төрле эшләр белән шөгыльләнәләр. Спорт белән дә дуслар, ял да итәләр. Шунысы мөһим, Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) сөннәтен үтәү аларның тормышында зур урын алып торырга тиеш. Иртәнге, кичке догаларны уку, әхлак кагыйдәләрен үтәү, мәсәлән. Сөннәт гамәлләрне никадәр күбрәк үтисең, хәтерләү сәләте шулкадәр яхшыра. Ә кирәкмәгән сүзләр сөйләү, гамәлләр кылу хәтерне начарайта. Шуңа күрә Коръәнне ятлау да авырлаша.

- Коръән ятлауга музыка зыян китерәме?

- Музыка тыңлау хәтта катгый тыела. Ә мөнәҗәтләр, нәшидләр тыңлау рөхсәт ителә. Аллаһны, Пәйгамбәребезне (с.г.в.) искә төшерергә сәбәп булсалар, әлбәттә.

- Башка хафизлар белән аралашасыңмы соң?

- Әйе. Без Таҗикстанда укыганда 40 студент идек, Россиядән, Үзбәкстан, Ингушетиядән килгән мөселман яшьләре бар иде.

- Синең өчен бу фани дөнья нәрсә ул?

- Коръәнне ятлаганчы бу дөньяны мин, гомумән, башкача күрә, аңлый идем. Аннан соң, минем өчен ул бөтенләй бүтән төс алды. Һәрвакыт Аллаһны үз яныңда тоясың, кайда гына булсаң да Аның рәхмәте сиңа ирешеп тора. Башка илләргә китсәң дә күңелең тыныч.

- Коръән ятлап, Аллаһ кануннары буенча яшәмәүчеләр дә бармы?

- Әлхәмдүлилләһ, бүгенге көндә коръәнхафизлар күп. Бу бит Аллаһның зур нигъмәте. Коръәнне ятлап та, Аллаһ кануннары буенча яшәмәүчеләр бу дөнья өчен, кеше күрсен дип тырышкан булып чыгалар. Моның өчен алар Аллаһ каршында җавап бирәчәк.

- Хәдис-шәрифтә: "Җәннәткә беренче керүче кеше ул - коръәнхафиз, тәмугка беренче керүче дә - коръәнхафиз", - диелә.

- Бар да нияттән тора. Әгәр дә дөрес ният куелмаган булса, кеше Коръәнне Мәккәгә барып ятлап кайтса да, Казанга кайткач онытачак. Шундыйлар да бар, Коръәнне тегендә-монда йөреп укыйлар, бу зур тәртипсезлек һәм хөрмәтсезлекне күрсәтә. Коръәннән бер генә хәреф уку да, изге гамәл булып тора бит. Әгәр кеше авырлык белән укый икән, укуын дәвам итсен. Чөнки аңа хафизлардан да күбрәк савап язылачак, иншә Аллаһ. Шундый хәдис бар: "Коръәннән бер генә хәреф тә булмаган кеше җимерелгән өйгә тиң" (Әт-Тирмизи).

- Синең матур итеп нәшидләр җырлавыңны да беләбез. "Зәйтүнә" республикакүләм дини мөнәҗәтләр фистивалендә төркемегез белән катнашып, җиңү дә яуладыгыз. Ничек уйлыйсың, мондый ярышлар үткәрү кирәк микән?

- Синең җырлавыңны халык көтсә, әгәр дә җырларың Аллаһ юлыннан атлар өчен аларга этәргеч булса, исламга мәхәббәт уятса, бу - бик яхшы гамәл. Ә җиңү, урыннар алу өчен ярышу мөселман өчен мөһим булырга тиеш түгел.

- Нәшидләр яздыру турында уйламыйсызмы?

- Башта Коръән яздырырбыз дигән ният булды. Продюсер риза булыр микән, дип бераз шикләнебрәк торган идек, әлхәмдүлилләһ, башкарып чыктык бу эшне. Ул диск дини уку йортларында укучылар өчен дәреслек ролен үти, сатуда да табарга була. Кабат кызык өчен генә музыкасыз бер нәшид яздырып карадым. Менә шулай башланып китте, тиздән нәшидләр белән диск та әзер булачак.

- Концертлар планнаштырыламы?

- Әлбәттә, ниятләр бар. Аллаһ теләсә, киләсе елда чыгышларыбыз башланачак. Төркемебездә дүрт кеше. Продюсерыбыз Марат Мухин белән клиплар әзерлибез. Мөселман туйларында чыгыш ясарга чакырып торалар...

- Уңышлар телим, Махфузулла, Аллаһ разый булсын!

Сөмбел ШӘРИФУЛЛИНА

ӨМЕТЛӘРНЕ АКЛАУЧЫ ЯШЬ ХӘЗРӘТ

Үзебезнең авыл егете Илнар Фәрхетдинов урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казанга мәдрәсәгә укырга барырга теләген белдереп, мәчет картларына мөрәҗәгать итә һәм юллама бирүләрен сорый. Егетнең төпле фикер йөртүен искә алып, имам вазыйфаларын башкаручы Динмөхәммәт хаҗи үзенең фатихасын бирә һәм Илнар Казанга мәдрәсәгә юл тота. Өч ел вакыт үтеп тә китә, мәдрәсәдә әйбәт кенә укып, кулына документ алып, Илнар кайтып та җитә. Динмөхәммәт хаҗи, сәламәтлеге какшау сәбәпле, имам-хатыйб вазыйфаларын башкаруны яшь хәзрәткә тапшыра.

Түбән Ушма авылы мәхәлләсе районда иң зурлардан санала. 400 дән артык хуҗалык кергән мәхәллә мәчетенең 110 еллык тарихы бар. 27х12 метрлы таш мәчетне тәртиптә тоту зур чыгымнар сорый, аның өстенә яшь хәзрәткә хезмәт хакы түләргә кирәк. Мәчет картлары, авыл халкы мәсьәләне уңай хәл итәләр, яшь хәзрәткә булышалар. Илнар авыл халкының ышанычын акларга тырыша, җиң сызганып эшкә керешә. Гасырдан артык тарихы булган мәчеткә ремонт ясала. Әмма мәчетне әйләндереп алган 170 метр озынлыктагы койма тәмам черреп беткән, аны тимер коймага алыштыру күп чыгымнар сорый. Тиз арада халыктан 95 мең сум акча җыела. Бу гына җитми, читтә яшәүче авылдашларга да мөрәҗәгать итәләр. Район хакимияте башлыгы Анатолий Иванов булышлыгы белән 300 мең сум акча тупланып, агач койма тимергә алыштырыла. Авыл халкы белән өмә ясап, мәчет тирәсен чистарталар.

Мәчетнең эчке һәм тышкы кыяфәтенә карап кына динне күтәреп булмый бит әле. Яшь хәзрәт бу эштә авылның өлкән абыстае - 40 ел мәктәптә балалар укыткан, үзлегеннән гарәп графикасын өйрәнеп, Коръәнне иркен укучы Асия абыстайга киңәш сорап бара. Яшь хәзрәт белән өлкән абыстай тиз арада уртак тел табалар һәм мәчеттә өлкән яшьтәге апалар белән дин сабаклары оештырыла. Мәктәп балалары да читтә калмый. Укучы балалар үзләренең класс җитәкчеләре белән һәр җомгада мәчеткә дин сабаклары алырга киләләр. Дини бәйрәмнәр вакытында мәчет гөрләп тора. Корбан һәм Ураза гаете көннәрендә мәчеттә энә төртерлек урын калмый, бигрәк тә яшьләр күп йөри. Мәүлид, рамазан айларында табын әзерләп мәҗлесләр уздырыла. Өлкән абыстай һәм хәзрәт үзләренең эчтәлекле вәгазьләре белән халык күңеленә үтеп керәләр. Авылдагы дини йолалар берсе дә алардан башка үтми. Яшь парларга никах уку, балага исем кушу, мәетне соңгы юлга озату йолаларын җиренә җиткереп башкаралар.

Бүгенге көндә мәчетебез гөрләп эшләп тора, дин тотучыларга барлык шартлар да тудырылган. Мәчеткә газ, су, электр кергән. Җомга намазларын халык җылыда, чишенеп укый. Мәчет манарасыннан намазга чакырып биш вакыт азан әйтелә. Җомга намазларына 50-60 кеше йөри, күп өлешен яшьләр тәшкил итә. Ел саен мәчеткә йөрүче картлар, абыстайлар белән Болгарга сәяхәтләр, балалар өчен Казандагы тарихи урыннарга экскурсияләр оештырыла. Хәзрәтебезнең мәчет өчен куйган хезмәтләре бик күп, халык арасында абруе зур, сөйләгән вәгазьләре халык күңеленә үтеп керә.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте авылларны яшь имамнар белән тәэмин итү һәм аларның эшләве өчен барлык шартлар тудыруны бурыч итеп куйды. Яшь имамнарга зур өметләр белән карый. Иншә Алла, киләчәктә Илнар хәзрәт бу ышанычны аклар, алга таба эшендә зур уңышлар теләп калабыз.

Рифкать ГАЛИЕВ,
Мамадыш районы,
Түбән Ушма авылы

"Таян Аллага!" әдәби конкурсы быел дүртенче тапкыр узды. Әлеге конкурс талантлы яшьләрне берләштерә торган чара һәм ул елдан-ел куәтләнә бара. Быелгы конкурста 50 дән артык кеше катнашты, узган ел 26 гына иде."Таян Аллага!" дигәчтен, аны дини тематикага язылган әсәрләр конкурсы дип уйлаучылар бар. Бу һич кенә дә алай түгел, безгә килгән эшләрнең күбесе әдәп-әхлак темасына язылган, Пәйгамбәребез (с.г.в.) тормышы турында әсәрләр, мөнәҗәтләр, хәтта бер киносценарий да бар иде.

Конкурс поэзия һәм проза номинациясендә узды. Өченче номинациядә балалар иҗатын билгеләдек. Аларның гомум әхлакый кыйммәтләрне күтәрүләре безне бик сөендерде.

"Дин вә мәгыйшәт" газетасы укучылары игътибарына Гран-при иясе Минневарис Мингалиевның (Вәрис Гали) "Кара сәет риваяте" дип исемләнгән хикәясеннән өзек һәм «Шигъърият» номинациясендә I урынны алган Нурфия Халикова шигырьләрен тәкъдим итәбез.

Айдар КАРИБУЛЛИН

Вәрис ГАЛИ:

КАРА СӘЕТ РИВАЯТЕ

(Хикәя)

ТАҢ беленә башлауга балыкка барырга ниятләп куйган идем. Кояш чыгар алдыннан Нократның Бәйҗан тавы артындагы борылышында берсеннән-берсе майлы, ярты-шар кило тарта торган кызыл канатлар бик яхшы чиртә. Кичтән изрәп йокыга киткәнмен, бер заман җәмәгатем касыгыма төрткәнгә сискәнеп торып утырдым.

- Кич буе җыенган идең. Балыгыңа бармаска булдың мәллә? - диде ул.

Таң сыеклыгы сизелә башлаган иде инде. Тиз генә сикереп тордым да, җиңелчә генә киенеп, чыгып йөгердем. Безнең йорт тау астында. Өстә - кечкенәрәк кенә парк. Элек анда борынгы зират булган, дип ишеткән бар. Кабат христиан руханиларын җирләүләрен совет заманнарында халык дошманнарын күмгәннәрен күршедәге бабай сөйләгән иде. Җәй көнендә үзебезнең бакчадан гына менәбез дә, шәһәргә шул парк аша йөрибез. Шуның өчен коймада кечкенә капка да калдырылган. Бу юлы да анда үзебезнең бакчадан гына күтәрелдем. Караңгыда кулларны чия ботаклары да сыдыргалады бугай. Паркка килеп кергәнче акация куаклары аша да узасы бар. Алар да тырнамыйча үткәрмәделәр.

Таң сызыла башлаган вакыт - җир өстенә бераз гына яктылык таралып килә. Әллә ничә ел яшәп, йөзәрләгән тапкыр узган булгач, күзне бәйләсәләр дә бу тирәләрдә адашып йөрмәячәгемә шикләнмим. Һәр карышында нәрсәләр ятканын ялгышмыйча әйтеп бирә алам. Тик бу юлы аякларыма күзгә күренмәс герләр асылган кебек иде. Җанны да нәрсәдер тырный. Акацияләр рәтен узып күп тә китмәдем, күзем Нократ буена төшә торган баскыч янындагы ике шәүләгә төште. Икесе дә аксыл саргылт төстәге озын күлмәкләрдән иде алар. Хатын-кызның эчке күлмәкләрен кигәннәр, дияр идең, болар ниндидер тоныграк төстә. Берсе хатын, икенчесе ир кеше, яшьләр. Кызының озын кара чәчләре иңнәренә таралып, биленә кадәр төшкән. Егетенең бил туры үрелгән бау белән буылган. Һәм анда кынысы белән хәнҗәр асылган. Шул хәнҗәрне күргәч, Кавказ ягыннан килгән кешеләр икән болар, дигән уй килде күңелемә. Киноларда аларның билләренә затлы хәнҗәр тагып йөргәннәренә игътибар иткәнем бар. Ара егерме-егерме биш метр чамасы гына булгач, таң сыеклыгында бу егетнең дә хәнҗәре җемелдәвек ташлар белән бизәлгәнен шәйләп алдым. Егет кызын иңнәреннән кочкан, ә тегесе аңа сыенып ук беткән. Иртәнге салкын үзәкләренә үткәндер, дигән уй йөгерде баштан. Елга буенда су салкыны да бар. Өйләренә кайтып ятсалар соң, төне буе йөрмәсәләр, дип, эчемнән генә әрләп тә алдым. Әмма миндә алар кайгысы түгел иде, балык кайгысы күтәрде иртүк хатын янындагы җылы урынымнан. Тегеләргә бер авыз сүз әйтмичә үз юлымда булдым.

Бәйҗан тавы артында балык бик шәп чиртә. Шуны уйлап тиз генә барып та җиттем мин анда. Яр буена алты-җиде кеше тезелгәннәр, мин хыялланган балыкларны бер-бер артлы тартып чыгара башлаганнар иде инде. Тау буе урамында яшәүче Ягүр дәдәйдән:

- Озак йоклый хәзер кеше, - дигән шелтә дә эләкте.

Дөрес сүзгә җавап юк. Элекке райком каршындагы паркка менгәч очраган кыз белән егет искә төшеп:

- Мамадышта төнлә су коена башлаганнар икән. Элеватор янындагы балыкларны качырып бетермәсәләр ярар инде, - дигән булдым.

Ягүр дәдәй ялт итеп борылып карады.

- Нәрсә, нәрсә дидең? Нинди су коенучылар? Кайда кемнәрне күрдең?

Көн шактый ачылган иде инде. Дулкынлануы йөзенә кызыл бөрчекләр булып бәреп чыкты. Дугаланып торучы борынына да таң чыгы каплаган кура җиләге төсе йөгерде. Кешенең кисәк шулай үзгәрүеннән үземә дә сер булып китте. Җыелма пластик кармагымны сүтеп челәүчән кисерттем дә суга ыргыттым.

- Кемнәрне очраттың? - дип төпченә башлады моңарчы сабыр гына холыклы күренгән Ягүр дәдәй. - Егет белән кыз, дидеңме?

- Әйе. Үзебезнең бакча башында, Нократка төшә торган баскыч янында озын аксыл күлмәкле хатын белән ир тора иде, - дип, теләмичә генә сөйләп бирдем.

Ягүр дәдәйгә әллә нәрсә булды.

- Ни, ни бит... алар бит... тегеләр... - дип, миңа нәрсәдер аңлатмакчы була башлады ул. Теле көрмәкләнүен шактый вакыт җиңә алмыйча торды әле.

Ахырдан:

- Алар Хәсәнҗан сәет белән Зөлхиҗҗә өрәкләре, - дигән сүзләрне кысып чыгара алды.

Үзем дә имәнеп киттем. Шушы яшемә җитеп, өрәкләр күргәнем юк иде әле. Аларны әкият, уйдырма дип кенә уйлый идем. Бу юлы да чираттагы сафсата дип кабул иттем. Эчке көлемсерәү белән:

- Нишләп йөриләр соң алар? - дип кенә куйдым.

Минем телдәге иронияга карт балыкчының исе дә китмәде.

- Бәхетең бар икән әле, - дип куйды ул, серле генә елмаеп. - Исән калгансың. Аларның үзләренә очраган кешене иярттеп киткәннәрен дә ишеткәнем бар. Без яшь чакларда бер егет югалды иртән шул бакча аша балыкка төшкәндә. Өрәкләре соңгы елларда күренми башлаган иде, тагын чыкканнар икән. Үзләренә яңа җаннар сорый торганнардыр.

Бу сүзләрдән мин дә өнсез калдым. Нинди җаннар? Әллә Ягүр дәдәй бутала башлаганмы соң? Нәрсәләр сөйли ул? Тузга язмаган нәрсәләрне дөрес булса да сөйләшмә, диләр бит. Картның бу сүзләре бернинди киртәләргә дә сыймый иде.

Шул вакыт кармак таягым кисәк тартылып куйды. Сөйләшүгә бирелеп, калкавычымны да күздән ычкындырганмын. Кармагымны күтәреп алмакчы булган идем, төптә нәрсәгәдер эләккәнме шунда, урыныннан да кымшанмый. Уңга да авыштырып, сулга да яткырып тартып карыйм, селкенми генә бит! Монысы тагын нәрсә соң? Чирткән кебек булган иде бит. Кармак җебем өчле, тиз генә өзелә торган түгел, өстәвенә чит илнеке әле. Рәхәтләнеп каерырга була. Сакланып кына күтәргәли башладым. Агач кисәге бугай, тырыша торгач, урыныннан кузгалгандай булды. Кармакның зыңлап тартылган кылына ияреп, салмак кына ярга якынлаша башлады. Бу тирәләрдә элек Мамадышка агач кисә торган урын булган диләр. Дөрестер. Урыны-урыны белән, чирәм араларында таралып ятучы ташкүмер кисәкләре дә очрый.

Кармакның зыңлап тартылган кылы ярга якынлашкан иде инде. Берзаман су өстенә авызы киереп ачылган олы гына капкара балык башы килеп чыкты. Бәләк кадәр бардыр! Җәен бит бу! Су бозавы! Тез буыннарым калтырап куйды. Әмма кармакны йомшартмадым. Балыкны күреп, ярдәмгә башкалар да килеп җитте. Берсе саңакларыннан эләктерергә дә өлгерде. Дәррәү ярга сөерәп чыгардык. Менә бу балык ичмасам! Моның кадәр зур балыкны беренче тотуым иде әле. Буыннарымның хәле китеп чирәмгә утырдым. Җәенне ярдан читкә үк алып киткәннәр иде.

- Егерме килодан артык тарта. Ничек чыгара алдың соң син аны? - дип, шаккаттылар егетләр.

Тел шартлатырлык та, гаҗәпләнерлек тә иде шул аның кадәр җәенне гап-гади кармак блән тартып чыгаруы. Койрыгын бер болгап җибәрсә дә, кылны шартлатып өзеп китә ала иде бит ул. Ходай үзе булышкандыр!

Егерме килолы җәен сөйрәп чыгару шатлыгыннан дөньям түгәрәкләнгән иде инде. Башкалар да дөньяларын оныттылар. Китте үзләре тоткан балыкларны искә алу... Кемдер ярты центнерлы җәен каптырган икән. Ягүр дәдәйнең Нократ төбеннән биш килолы кысла сөйрәп чыгарганы булган... Бөтенесе кармакларын онытты. Башка балык тотарга теләкләре дә сүнгән иде бугай. Биштәрләрен күтәреп килеп, җәен тирәли түгәрәк ясап утырдылар.

- Бүген, энекәш, синең бәйрәм. Көн саен мондый малны эләктереп булмый. Кеше үз гомерендә сагынып искә алырлык бер балык та тота алмаска мөмкин. Син бу яктан бәхетле.

Ягүрнең бая ук нәрсәдер сөйлисе килгәнен, әмма тыелып торганын сизгән идем инде ул. Башкаларның сүзләре бераз басыла төшкәч:

- Әйт инде сүзеңне. Барыбер эчеңне тырный бит, - дип үзем сүз башладым.

Карт әйтергәме, юкмы, дипме, әллә нәрсәдән сүз башларга белмичәме, кабызган тәмәкесен тартып бетермичә уйларына чумып утырды.

- Син күргән егет белән кыз - Хәсәнҗан сәет белән Зөлхиҗҗә өрәкләре - күптән күренгәннәре юк иде инде. Бу хәл юкка түгел. Җаннары яңадан уянган, - диде карт. Бөтенесе шым булды, карашлар Ягүргә төбәлде.

- Кемнәр соң алар? - дип сорамый түзмәдем.

Үз бакча башыңда өрәкләр күр дә, кемнәрнеке икәнен дә белмә!

- Бу вакыйга бик борынгы заманнарга барып тоташа. Болгар бабайларыбыз заманнарына ук. Бик гыйбрәтле риваяте дә бар. Ирекмәсәгез, тыңлагыз, - дип сөйләп китте ул.

Барыбыз да шым булып аны тыңларга әзерләндек...

Нурфия ХАЛИКОВА

Бәхет дигән түшенчә юк

Бәхет дигән төшенчә юк,
Без сөенә белмибез.
Авыр хәлдә калучыга
Хәер бирә белмибез.
Кызгану хисен җуйганбыз,
Кая ул сабыр булу...
Гарип-горәбәләр күреп,
Әз генә тыйнак булу...
Кешенеке кештәктә шул,
Үзебезнеке булсын.
Кирәкме-юкмы уйламыйк:
Өсте-өсте мал булсын.
Тирә-якта кемнәр яши,
Юкмы ятим балалар?
Авыру, хәлсез бәндәләр-
Бу турыда кем уйлар?
Бәхет дигән төшенчә юк,
Без сөенә белмибез...
Иң мөһиме: кирәк чакта,
КЕШЕ була белмибез....

Гомер арбасында уйланулар...

Гомер мизгел, сизмичә дә
Калабыз үткәннәрен.
Кочак тулы, кая куйыйм:
Гаебем, үпкәләрем?
Кемнедер каты рәнҗеттем,
Кемнеңдер миндә яше.
Мине дә үпкәләттеләр,
Һаман онытмый яшим...
Аллаһтан безгә бирелгән-
Гомер ул кыска гына.
Кадерләрне исән чакта
Белер мизгелдә тына...
Соңга калулар язмасын,
Үкенеч кемгә хаҗәт?!
Бер-береңә кирәклекне
Белеп яшәсәк бик шәп.
Аңлашып яшәсәк иде-
Күз карашыннан гына.
Ыгы-зыгы, борчуларны
Якын җибәрми янга.
Таш белән атканнарга да,
Аш атар көчен табыйк.
Ачуны тышка чыгармый,
Һаман да алга атлыйк.
Аллаһ бездән риза булсын,
Аллаһ кушканча яшик!

Укы Коръән

Ата-бабам мирасының зуры -
Коръән тора өйнең түрендә.
Сабый чактан белгән
догаларым
Тел очында йөри гомергә.
Укы, балам, уят йөрәкләрдә
Иман нурын, Коръән хаклыгын.
Сине тыңлап искә алсын
һәркем
Дөньялыкта Аллаһ барлыгын.
Бисмилласыз дөнья
куып булмый,
Гамәл дәфтәребез янәшә.
Нәсел-ыру дәверләрне җиңеп,
Динле булыйк диеп көрәшә.
Үзебезме, әллә Коръән елый(?)
Ни яшерә төннең карасы?
Без - мөселман өммәтеннән!
Шуны
Онытма син адәм баласы.
Укы, балам, уят йөрәкләрдә
Иман нурын, Коръән хаклыгын.
Сине тыңлап искә
алсын һәркем
Дөньялыкта Аллаһ барлыгын.

Хаҗга әзерләнәбез

Гомрә белән хаҗ арасында нинди аерма бар?

Гомрә елның теләсә кайсы вакытында башкарыла ала, ә ХАҖ - бары тик зөлхиҗҗә аенда гына. Гомереңә бер тапкыр булса да хаҗ кылу - һәр мөселман өчен фарыз булып исәпләнә, ә гомрә - сөннәт гамәлләрдән санала.

Ихрам нәрсә була?

Ихрам - хаҗ кылучының рухый пакьлегенең аерым бер халәте. Ихрамга керер өчен госел алырга, аның махсус киемнәрен кияргә һәм ихрам кагыйдәләрен үтәргә кирәк.

Ихрам вакытында нәрсәләр тыела?

Ихрамда булганда түбәндәге гамәлләрне башкарырга рөхсәт ителми:



● Әшәке сүзләр әйтү, сүгенү.

● Тыелган гамәлләрне башкару.

● Бәхәскә керү. Коръәндә болай дип әйтелгән: "Хаҗ кылу мәгълүм булган айлар. Берәү хаҗ кылырга ниятләп ихрам багласа, хаҗ гамәлләре тәмам булганчы якынлык кылу, шәригатькә хилаф булган эшләрне эшләү һәм юлдашлар белән низаглашу һич дөрес булмый..." (2:197).

● Кыр хайваннарын аулау һәм үтерү. Коръәндә бу җәһәттән болай диелгән: "Хаҗ сәфәреңдә ихрам баглаган хәлдә кыр хайваннарын ауламагыз!..." (5:95).

● Аучыга ау вакытында ярдәм итү.

● Тегелгән кием кию.

● Перчаткалар яки аякны тубыкка кадәр каплаган аяк киемнәре кию.

● Башны яки йөзне каплап йөрү.

● Хушбуйлар куллану. Пәйгамбәр (с.г.в.) дөя үтергән кеше турында болай дип әйткән: "Аңа хушбуй сөртмәгез". Бу хәдисне әл-Бохари һәм Мөслим китерә.

● Чәч алдыру.

● Тырнак кисү.

● Хуш ис сеңгән ниндидер кием кию. Ибне Гомәр Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) шундый сүзләрен тапшыра: "Гөлчәчәк яки шәфран эләккән киемне кимәгез, ләкин, кием аннан соң юылган булса, моңа рөхсәт бар". Хәдисне әт-Тәхәви китерә.

● Җенси мөнәсәбәткә керү.

Мәккәгә барганда ихрамга кайда керергә кирәк?

Микат - дөньяның төрле җирләреннән җыелып хаҗ кылырга баручы мөселманнар, ихрамга керми торып, шул чикне үтеп чыгарга тиеш булмаган билгеле бер урыннардыр ул. Әгәр дә микат очкыч (самолёт) яки автобус кебек транспорт чарасы белән үтелсә, мөселманнар ихрамга алдан, микатка җиткәнче үк керергә тиеш. Моны аэропортта, вокзалда яки транспорт чарасының үзендә башкарырга була.

Бер мөселман икенче бер кеше өчен хаҗ кыла аламы?

Хаҗ кыла ала. Үзең өчен башка берәүне хаҗ кылырга җибәргәндә, үзенең фарыз хаҗын башкарган кешене җибәрү яхшырак. Әле үзе өчен дә хаҗ кылмаган кешене үзең өчен хаҗ кылырга җибәрү мәкруһ гамәл булып санала, ләкин, шулай булса да, андый хаҗ кабул ителә. Хаҗ кылу өчен матди мөмкинлекләре булып та, әле хаҗ кылмаган кеше башка кешеләр өчен хаҗ кылырга тиеш түгел, ул башта үзе өчен хаҗ кылырга тиеш.

Олы яшьтә булган, карт кешеләргә хаҗ кылу өчен башка кешеләрне җибәрергә ярыймы?

Әгәр мөэмин-мөселман кешенең хаҗ кылу йолаларын башкарырга үзенең хәленнән килсә, аның үзенә хаҗ кылу зарур. Әгәр дә инде ул бик нык картайган булып, хаҗ кылу өчен аның сәламәтлеге җитмәсә һәм аның сәламәтлеге яхшыруга өмет тә булмаса, андый очракта аның өчен икенче бер кеше хаҗ кыла ала.

Хатын-кызларга ирләре яки туганнарыннан башка хаҗ кылырга ярыймы?

Әгәр хатын-кыз хаҗ гамәлләрен берүзе башкарса, аның бу хаҗы кабул ителә, ләкин, иреннән яки якын туганнарыннан башка хатын-кызга сәфәргә чыгу - исламда тыелган һәм ул гөнаһ булып санала. Әгәр дә хатын-кыз Мәккәдә яшәсә, ул хаҗ кылу йолаларын берүзе генә башкара ала, ләкин, аның хаҗны ире яки мәхрәме (якын ир-ат туганы) белән бергә башкаруы күркәмрәк булып исәпләнә.

Бурычлар булган вакытта хаҗ кылу.

Башта бурычларны түләп бетереп, аннары гына хаҗ кылу яхшырак. Әгәр сезнең бурычларыгызны каплар өчен тиешле мөмкинлекләрегез булса һәм хаҗ кылу аның өчен берниндидә мәшәкать тудырмаса, бу вакытта сез тыныч күңел белән хаҗ кыла аласыз һәм сезнең бу хаҗыгыз кабул ителәчәк.

Хаҗ яки гомрә кылырга бару өчен ата-аналарның рөхсәтен алырга кирәкме?

Хаҗ яки гомрә кылу өчен ата-анадан рөхсәт алу таләп ителми. Әгәр сез алар белән киңәшләшсәгез һәм аларның рөхсәтен, хәер-фатыйхасын, изге теләкләрен алып хаҗ кылырга китсәгез - күпкә яхшырак һәм хәерлерәк булыр. Бу очракта сезнең кайдан юл тотуыгыз мөһим түгел, сез юлга Дубайдан чыгасызмы, әллә инде үз илегездәнме. Исламда әти-әниләрнең дәрәҗәсе бик югары.

Бер барганда берничә гомрә кылырга ярыймы?

Изге Мәккәдә булганда, сез күпме телисез, шулкадәр гомрә кылырга мөмкинсез. Әгәр дә кеше Мәккәдә унбиш көннән дә озагракка калса, яңа ихрамны микатта яки Гайшә мәчете янында кияләр. Ләкин шунысын әйтеп китәргә кирәк: яңа ихрам сез элекке ихрамнан тулысынча арынганда гына (ягъни сез тәваф һәм сай кылганнан соң һәм чәчегезне алдырганнан соң гына) киелә.

Гомрә ничек башкарыла?

Микатта яки аңа килеп җиткәнче ихрамга керәсез. Ягъни, тәһарәт алып, ике рәкәгать намаз укыйсыз һәм тәлбия әйтегез ("Ләббәйкә..."). Шуннан соң Мәккәгә юнәләсез һәм Кәгъбәне җиде кат урап чыгасыз. Шуннары Ибраһим галәйһиссәлам торган урында ике рәкәгать намаз укыйсыз. Намаз укыгач, Сафа һәм Мәрвә таулары арасында сай кыласыз һәм чәчегезне алдырасыз. Шуның белән гомрә тәмам була, сез ихрамнан чыккан булып исәпләнәсез.

Ихрам вакытында кешеләр, тәннең аскы һәм өске өлешләрен каплар өчен, гади кием урынына ике кисәк тукымадан файдаланырга, ә ихрам тәмам булгач, чәчләрен алдырырга тиеш. Хатын-кызлар исә, чәчләрен ике бармак очы кадәр озынлыкта кисә. Аннан тыш, ир-атларның, хатын-кызлардан аермалы буларак, ихрам вакытында башлары капланган булырга тиеш түгел.

Хаҗ вакытында кайда корбан чалырга була?

Хаҗ гамәлләрендә каралган корбан чалуны (мәсәлән, дәмм тәмәттугны, кыйранны, ихсарны яки җәнабатны) бары тик Хәрәм җирләрендә генә башкарырга кирәк. Корбан гаетендәге (моның өчен матди мөмкинлекләре булган кешеләргә фарыз булган) корбан чалуларны Хәрәм җирләрендә дә, үз илеңдә дә башкарырга була.

Олы яшьтә булган, карт хатын-кызга башка хатын-кыз туганнары белән бергә, мәхрәмнән башка гына, хаҗ кылырга бару ярыймы?

Хәнәфи мәзһәбе буенча, хатын-кызга мәхрәмнән башка (якын туганыннан башка) хаҗ кылырга бару ярамый. Ләкин, Согуд Гарәбстаны Корольлеге кануннары буенча, 45 яшьтән өлкәнрәк хатын-кызлар өчен чикләүләр азрак, андый хатын-кыз изге җирләргә мәхрәмнән башка да бара ала.

Мәккәгә хаҗ кылырга бару өчен кредит алырга ярыймы?

Коръән һәм хәдисләр процентлы кредит алуны тыя һәм андый кредит алучыларны нык кисәтә. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам процент алучыларга, процент түләүчеләргә, шуны язып баручыларга һәм шулар буенча шаһитлек бирүчеләргә ләгънәт укыган. Хаҗ һәм гомрә - гыйбадәтләр һәм алар өчен тыелганнарны куллану - яхшы эш түгел.

Әгәр дә банк кредитларын түләп бетермәгән булсаң, хаҗга барырга ярыймы?

Процентлы банк кредитын, аларга кичектергесез зарурлык булмаса, алырга ярамый. Әгәр сез үзегезнең мәгълүматсызлыгыгыз аркасында кредит алгансыз икән, хаҗ сәфәренә чыкканга кадәр сезгә аны түләп бетерергә кирәк. Әгәр дә банк кредитны хәзер үк капларга дип таләп куймый һәм сезнең, хаҗ кылып кайтканнан соң, аны тулысынча каплый алуыгызда ышанычыгыз бар икән, бу вакытта хаҗ кылу дөрес була.

Намаз укымасаң, хаҗ кылырга ярыймы?

Ярый. Хаҗ һәм намаз - исламның төрле баганалары һәм Кыямәт көнне хаҗ һәм намаз өчен аерым-аерым җавап тотарга туры киләчәк. Намаз укымаган күп кешеләр хаҗ кыла һәм шуның нәтиҗәсендә намаз укый, хәрәмнән тыела, гомумән, исламга җаваплырак карый башлый.

Кемнәр хаҗ кыла ала?

Балигълык яшенә җиткән, үз акылында булган, хаҗ кылу өчен финанс һәм физик мөмкинлекләре булган һәр мөэмингә гомеренә бер тапкыр булса да хаҗ кылу фарыз. Хаҗ кылу балалар, авырулар һәм аның өчен финанс мөмкинлекләре булмаган кешеләр өчен фарыз түгел.

Хаҗ кылу өчен күпме вакыт китә?

Гадәттә 5-6 көн.

Гомрә кылу өчен күпме вакыт җитә?

Берничә сәгать.

Хаҗ кылырга бару өчен нинди медицина таләпләре куела?

Хаҗ кылырга бару өчен түбәндәге белешмәләрне җыярга кирәк:

● бүлек табибыннан сәламәтлек турында белешмә;

● яшәгән урыныңнан хәнакка (дифтериягә) каршы прививка эшләнүе турында белешмә;

● менингитка каршы прививка (дүрт компонентлы вакцина) эшләнүе турында белешмә.

Хаҗны өч төргә аерып карарга мөмкин:

Ифрад хаҗы - гомрәдән (кече хаҗдан) башка гына хаҗ кылу; хаҗ кылучы ихрам (ак тукыма) кия, хаҗ кылу өчен генә ният кыла һәм хаҗ бурычларын гына үти; ифрад хаҗы кылу өчен корбан чалу ваҗиб гамәлләрдән саналмый.

Тәмәттуг хаҗы - һәрбер кеше аерым ихрамга кереп, бербер артлы гомрә дә, хаҗ да кыла; хаҗ кылучы гомрә өчен ихрамга керә; кече хаҗ кылгач, ихрамнан чыга һәм, хаҗ вакыты җиткәч, хаҗ кылу өчен яңадан ихрамга керә. Тәмәттуг хаҗы кылучылар өчен корбан чалу ваҗиб булып санала.

Кыйран хаҗы - гомрәне дә, хаҗны да бер ихрамда кылу дигән сүз: ихрамга кергән вакытта хаҗ кылучы хаҗга да, гомрәгә дә ният кыла. Ул башта гомрә, ә аннары ихрамнан чыкмыйча гына хаҗ кыла. Кыйран хаҗы кылучы өчен корбан чалу шулай ук ваҗиб булып тора.

Хаҗ кылырга җыенган кеше, үз теләгенә карап, бу өч төрле хаҗның теләсә кайсына ният кылырга мөмкин - бар шартларын да үтәгән вакытта, аларның һәрберсе дә дөрес санала.

ДОГАЛЫ КИТАПЛАР

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең "Хузур" нәшрият йорты күңелләрне рухи яктан баету һәм ислам кыйммәтләрен тарату максатыннан китаплар нәшер итүне дәвам итә. Күптән түгел генә киң катлам укучыларга, имамнарга, башлангыч дини белем бирүчеләргә аталган яңа басмалар тәкъдим ителде.

Шуларның беренчесе - Татарстанның баш казые, Балтач районы имам-мөхтәсибе, танылган вәгазьче Җәлил хәзрәт Фазлыев туплаган "Локман Хәким нәсыйхәтләре"нең тулыландырылган икенче басмасы. Коръәндә исеме телгә алынган хикмәт иясе Локман Хәким Дауд галәйһиссәлам заманында яшәгән булса да, аның зирәк нәсыйхәтләре бүгенге көн өчен дә әһәмиятле. "Бу китап барлык кешеләр өчен дә көндәлек кулланма - өстәл китабы булып тора ала. Бу- бер кат укып чыгар өчен генә түгел, үзең өстендә эшләү, нәсыйхәтләрне тормышта куллану өчен",- диелгән басманың кереш өлешендә. Җәлил хәзрәт китапта һәркемгә аңлаешлы җиңел тел һәм тормышчан мисаллар белән Изге китапта язылганнарны, Локман Хәким нәсыйхәтләрен аңлатып бирә.

Татар телендә дөнья күргән икенче басманы дин белгече Фәрид хәзрәт Сәлмән әзерләгән. "Аятел-Көрси тәфсире" дип аталган китапта Коръәннең иң бөек аяте саналучы Аятел-Көрси тәфсир ителә, аны дөрес уку тәртипләре, мәгънәви үзенчәлекләре, серләре, фазыйләтләре җентекләп аңлатыла. Аллаһы Тәгалә көрсие, аять эчендәге илаһи мәсьәләләр хакында мәгълүмат бирелә. "Аятел-Көрси"не кайсы вакытта, кайсы урында укыганда нинди саваплар бирүе хакында да әйтелә. Басмадагы бүлекләр үк шуңа ишарә ясый: "Бәрәкәт арттыручы аять", "Саклаучы аять", "Аятел-Көрсинең серләре" һәм башкалар. Китапны кулына алган һәркемгә күркәм аятьне укырга һәм аның шифасын, сихәтен тоярга, рухын ныгытырга һәм тормышын бәрәкәтле итәргә язсын.

Өченче җыентык - "Авыр вакытларда укыла торган догалар" китабы. Басма кечкенә форматлы булса да зур бер рухи кыйммәткә ия, чөнки анда инсанның Аллаһы Тәгаләгә юнәлүен күрсәтүче догалар тупланган. Психологлар тарафыннан ясалган тикшеренүләр буенча, дога - илаһи ярдәм алу өчен рухи механизм, аны бөтен кеше дә куллана ала. Дәвамлы дога кылган кешеләрдә бурыч һәм җаваплылык тойгысы арта, көнләшү һәм явызлык кылу теләге кими. Дога һәркайсыбызга начарлыкларга һәм газапларга каршы сабырлык, көч бирүче шифадыр. Ислам башка гыйбадәтләрендәге кебек, догада да билгеле бер шартларның үтәлүен таләп итә. Дога кылу әдәпләре турында, билгеле бер вакытларда кайсы доганы укырга кирәклеге хакында китапта ачык язылган. Китап кечкенә форматта басылганга күрә аны үзең белән йөртергә дә уңайлы.

Айзирәк ГӘРӘЕВА

"ХУЗУР" нәшрият йортының сайты - huzur.ru;
Казандагы кибетләре адреслары: Лобачевский урамы, 6 нчы йорт һәм Газовая урамы, 19 нчы йорт; заказ бирү өчен телефоннар: (8843) 2-02-07-74, 8 (96 5) 596 55 37.

КАЗАН ТӘМЛЕТАМАКЛАРЫНА ГАРӘП КҮЧТӘНӘЧЕ

BATEEL бутигы - хөрмәнең 20 сорты; шоколадлы, цукат һәм чикләвекле хөрмәләр; табигый шоколад; Италиядә җитештерелгән зәйтүн мае; Согуд Гарәбстаныннан китерелгән гарәп каһвәсе.

BATEEL, югары сыйфатлы хөрмә бренды булудан башлап, затлы азык-төлекләр базарында иң данлыклы маркага әверелде. Дөньяның уналты илендә уңыш казанган зиннәтле BATEEL бутиклары, кафелары Лондоннан алып Джакартага кадәрле бик күп мегаполисларның эре сәүдә үзәкләрен бизи.

BATEEL бутигында продуктларның искитмәле түменнән башлап бизәк төшерелгән поднос рәвешендәге оформлениегә кадәр бар да купшы һәм кабатланмас - сатып алучылар үзләрен нәкъ көнчыгыш әкиятендәгедәй хис итәр.

Аллаһ Рәсүле (салләллаһу галәйһи вәссәлам) болай дигән: "Хөрмә оҗмах җимеше. Ул агуланудан дәвалау үзлегенә ия" (Тирмизи: Тыбб, 22).

BATEEL брендын чын тәмлетамаклар сайлый.

ЙОН ҖЕПТӘН ДИСБЕ

Дисбеләрдән төрле диннәрне тотучылар файдалана. Бүгенге көндә аларны нинди генә чималдан ясамыйлар: агачтан һәм пластиктан, күннән, җимеш төшләре, орлыклардан, коралл һәм энҗеләрдән, кыйммәтле минераллардан һәм хәтта алтын белән көмештән дә коялар. Ә менә минем танышым Роман Смольняков аларны ... йон җебеннән үрә! Бу дисбеләрне беренче тапкыр күргән кешеләр гаҗәпләнү һәм соклану хисләрен берничек тә яшереп кала алмыйлар.

"Мөселман дисбеләрен бик яратып үрәм. Моның өчен ике-өч көн вакыт кирәк, - дип сөйли Роман яраткан шөгыле турында. - "Кытай төене" дип аталучы үрү ысулын очраклы рәвештә генә эзләп таптым. Әлеге үрү сәнгате борынгы Кытайда һәм Япониядә барлыкка килгән һәм дөньяның башка илләренә дә таралган. Күпләргә ул гаять катлаулы ысул булып тоела. Моның өчен дөя һәм сарык йоннарын кушып нык итеп эрләгән, юып киптерелгән 70-100 метр озынлыктагы җеп кирәк. Мондый җептән төеннәр төгәлрәк, ә дисбеләр рельефлырак һәм пөхтәрәк килеп чыга", - ди Роман.

Үтә зур тырышлык һәм сабырлык белән үргән бу дисбеләр дини бәйрәмнәрдә үзенчәлекле, һәркемнең күңеленә хуш килерлек кадерле бүләк була ала. Өстәвенә дисбе үрүченең уңай энергетикасы да кушылса... Роман үзе бик тәртипле, әдәпле егет. Соңгы вакытларда ислам дине белән кызыксына. Коръәннең төрле тәрҗемәләрен чагыштыра-чагыштыра укый, гарәпчә нөсхәсен дә сатып алган. "Ул - өемнең түрендә. Кем белә, бәлки, кайчан да булса, гарәпчә өйрәнеп, мин аны укып та чыгармын әле", - ди Роман.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА
Роза ХУҖИНА фотосы

Хөрмәтле мөселман кардәшләребез!

Мәчетебезне төзеп бетерүдә ярдәм күрсәтүегезне сорап, сезгә Әмәт бистәсе мөселманнары исеменнән мөрәҗәгать итәбез.

БЕЗНЕҢ РЕКВИЗИТЛАР:

Приход п. Ометьево Казанского Мухтасибата
р/с 40703810100000000303
ИНН 1655064078
КПП 165501001
Банк реквизитлары (ОАО АИКБ "Татфондбанк", Казан шәһ.)
БИК: 049205815
К/счёт 30101810100000000815 в ГРКЦ НБ РТ

Мәчет имамының телефон номеры: 89297288860

ДИН вә Мәгыйшәт

Гамәлгә куючы: Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27).*
Нәшир: "Хузур" нәшрият йорты *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 10в).*

Май саны, № 5 (226)
Баш мөхәррир: Нияз САБИРҖАНОВ
Мөхәррир: Нәүбәһар КӘБИРОВА
Дизайнер: Гүзәл МИҢНУЛЛИНА
Корректор: Айгөл КРОХИНА
Газета логотибы **хәттат** Рамил НАСЫЙБУЛЛОВ тарафыннан эшләнде

Редакция советы:
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе ***Камил СӘМИГУЛЛИН;***
"Хузур" нәшрият йорты директоры ***Ришат ХӘМИДУЛЛИН;***
Татарстан мөфтие урынбасары ***Нияз САБИРОВ;***
Татарстанның баш казые ***Җәлил ФАЗЛЫЕВ;***
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы рәисе ***Габдулла ӘДһӘМОВ.***

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).
Заказ № 09611
Тираж: 10 мең данә
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя – 6 сум.
График буенча бу санга **21 нче апрель көнне 18.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде. **Кул куелды: 18.00 сәгатьтә.**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
Электрон адрес: niyaz-kazan@yandex.ru
Телефон: +7 (843) 267-29-67.

Язылу индексы: 16046
Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин.

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан саклагыз!